**МИНИСТЕРСТВО СПОРТА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ СПОРТ МИНИСТРЛЫГЫ**

---

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

22.06.2021 Казан шәһәре № 234

Татарстан Республикасы Спорт министрлыгының 2019 елның 7 октябрендә кул куелган 307 номерлы боерыгы тарафыннан расланган «Спорт мастерлыгына кандидат» һәм «беренче спорт разряды» спорт разрядларын, спорт хөкемдарларының «беренче категорияле спорт хөкемдары» квалификация категориясен бирү, мәхрүм итү, торгызу һәм Россия Федерациясе Спорт министрлыгына спорт исемнәрен, «бөтенроссия категорияле спорт хөкемдары» квалификация категориясен бирү, мәхрүм итү, торгызу өчен тәкъдимнәр юллау буенча дәүләт хезмәте күрсәтү буенча административ регламентка үзгәрешләр кертү турында

2010 елның 27 июленнән «Дәүләт һәм муниципаль хезмәт күрсәтүләрне оештыру турында» 210-ФЗ номерлы Федераль законы нигезендә һәм 2010 елның 2 ноябрендә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма органнары тарафыннан дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең административ регламентларын эшләү һәм раслау тәртибен раслау турында һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының аерым карарларына үзгәрешләр

кертү турында» 880 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма органнары тарафыннан дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең административ регламентларын эшләү һәм раслау тәртибе нигезендә

**б о е р а м:**

1. Татарстан Республикасы Спорт министрлыгының 2019 елның 7 октябрендә кул куелган 307 номерлы боерыгы (Татарстан Республикасы Спорт министрлыгының 2019 елның 11 ноябрендә кул куелган 356 номерлы боерыгы белән кертелгән үзгәрешләрне истә тоткан хәлдә) тарафыннан расланган «Спорт мастерлыгына кандидат» һәм «беренче спорт разряды» спорт разрядларын, спорт хөкемдарларының «беренче категорияле спорт хөкемдары» квалификация категориясен бирү, мәхрүм итү, торгызу һәм Россия Федерациясе Спорт министрлыгына спорт исемнәрен, «бөтенроссия категорияле спорт хөкемдары» квалификация категориясен бирү, мәхрүм итү, торгызу өчен тәкъдимнәр юллау буенча дәүләт хезмәте күрсәтү буенча административ регламентка үзгәрешләр кертергә һәм аны яңа редакциядә тәкъдим итәргә (беркетелә).

2. Әлеге боерыкның үтәлешен тикшерүне министрның беренче урынбасары Х.Х.Шәйхетдиновка йөкләргә.

Министр вазыйфаларын башкаручы Х.Х.Шәйхетдинов

Татарстан Республикасы
Спорт министрлыгының
2019 елның 7 октябреннән
307 нче номерлы (Татарстан
Республикасы Спорт
министрлыгының 2021 елның
22 июненнән кул куелган
234 номерлы боерыгы
редакциясендә) боерыгы белән
расланды

**Татарстан Республикасы Спорт министрлыгының 2019 елның 7 октябрендә кул куелган 307 номерлы боерыгы тарафыннан расланган «Спорт мастерлыгына кандидат» һәм «беренче спорт разряды» спорт разрядларын, спорт хөкемдарларының «беренче категорияле спорт хөкемдары» квалификация категориясен бирү, мәхрүм итү, торгызу һәм Россия Федерациясе Спорт министрлыгына спорт исемнәрен, «бөтенроссия категорияле спорт хөкемдары» квалификация категориясен бирү, мәхрүм итү, торгызу өчен тәкъдимнәр юллау буенча дәүләт хезмәте күрсәтү буенча административ регламент**

## 1. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Әлеге Регламент Татарстан Республикасы территориясендә «Спорт мастерлыгына кандидат» һәм «беренче спорт разряды» спорт разрядларын, спорт хөкемдарларының «беренче категорияле спорт хөкемдары» квалификация категориясен бирү, мәхрүм итү, торгызу һәм Россия Федерациясе Спорт министрлыгына спорт исемнәрен, «бөтенроссия категорияле спорт хөкемдары» квалификация категориясен бирү, мәхрүм итү, торгызу өчен тәкъдимнәр юллау буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең (алга таба – дәүләт хезмәте) стандартын һәм тәртибен билгели.

1.2. Дәүләт хезмәте алучылар: физик затлар - Россия Федерациясе гражданнары, регионнардагы спорт федерацияләре яки Татарстан Республикасында федераль орган бүлекчәләре (алга таба – гариза бирүче).

1.3. Дәүләт хезмәте Татарстан Республикасы Спорт министрлыгы (алга таба – Министрлык) тарафыннан күрсәтелә.

1.3.1. Министрлыкның урнашу урыны: Татарстан Республикасы, Казан ш.,

Петербург ур., 12.

Министрлыкның эш тәртибе: шимбә һәм якшәмбедән кала һәр көнне, дүшәмбе-җомга 9.00 дан алып 18.00га кадәр, төшке аш – 12.30-13.30.

Гаризалар кабул итү тәртибе: шимбә һәм якшәмбедән кала һәр көнне, Министрлыкның эш сәгатьләре вакытында.

Җәмәгать транспорты белән «Божра» тукталышына кадәр:

- 1, 91, 35а, 37, 29, 90, 71, 47 нче номерлы автобуслар белән;
- 2, 7, 17, 6, 8, 12 нче номерлы троллейбуслар белән;
- метро белән «Тукай мәйданы» станциясенә кадәр килергә.

Территориягә рөхсәт кәгазе һәм (яисә) шәхесне раслый торган документ белән керергә мөмкин.

1.3.2. Дәүләт хезмәтен күрсәтү тәртибе һәм аны башкару барышы турында хәбәр җиткерүне Министрлыкның Югары казанышлар спорты бүлеге (алга таба – Бүлек) (843) 221-81-19 телефон номеры аша тормышка ашыра.

1.3.3. Министрлыкның «Интернет» мәгълүмати-телекоммуникация челтәрендәге (алга таба – Министрлыкның рәсми сайты һәм «Интернет» челтәре) «Татарстан Республикасының рәсми порталы» Татарстан Республикасы дәүләт мәгълүмати системасы составына керә торган рәсми сайты адресы: http://minsport.tatarstan.ru/

1.3.4. Дәүләт хезмәте турында мәгълүматны түбәндәге юллар буенча алырга мөмкин:

1) Министрлык биналарында Гариза бирүчеләр белән эшләү өчен урнаштырылган дәүләт хезмәте турында визуаль һәм текст рәвешендәге мәгълүматны үз эченә алган мәгълүмати стендлар аша;

2) «Интернет» челтәре аша:

Министрлыкның рәсми сайтында (http://minsport.tatarstan.ru/);

Татарстан Республикасы Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталында (http://uslugi.tatarstan.ru/);

Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләренең (функцияләрнең) бердәм порталында (http://gosuslugi.ru/).

3) Министрлыкка телдән (шәхсән яки телефон аша) мөрәҗәгать иткән чакта;

4) Министрлыкка язмача (шул исәптән электрон документ рәвешендә) мөрәҗәгать иткән вакытта.

1.3.5. Министрлыкның урнашкан урыны, белешмә өчен телефоннары, эш тәртибе, рәсми сайты, шулай ук электрон почтасы мәгълүмат-аналитик тәэмин итү һәм халыкара эшчәнлек бүлеге белгече тарафыннан Министрлыкның рәсми сайтында, «Татарстан Республикасының дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр реестры» дәүләт

мәгълүмат системасында һәм Татарстан Республикасының Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталына урнаштырыла.

Гариза бирүчеләр белән эшләү өчен Министрлык биналарындагы мәгълүмат стендларында урнаштырыла торган мәгълүмат әлеге Регламентның 1.3.1, 2.1, 2.3, 2.4, 2.5, 2.7, 2.9, 2.11, 5.1 пунктларындагы белешмәләрне үз эченә алган дәүләт хезмәте турында Татарстан Республикасы дәүләт телләрендәге мәгълүматны үз эченә ала.

1.3.6. Бердәм порталда, Республика порталында Республика реестрындагы белешмәләр нигезендә дәүләт хезмәте күрсәтү тәртибе һәм вакытлары турында мәгълүмат гариза бирүчегә бушлай бирелә.

Дәүләт хезмәте күрсәтүнең вакытлары һәм тәртибе турында мәгълүматка керү мөрәҗәгать итүче нинди дә булса таләпләрне үтәмичә, шул исәптән мөрәҗәгать итүченең техник чараларына түләү алуны, мөрәҗәгать итүченең теркәлүен яки авторизацияләвен яки аның шәхси мәгълүматларын кертүне күз алдында тоткан программа белән тәэминат итүнең хокук иясе белән лицензияле яки башка килешү төзүне таләп итә торган программа белән тәэмин итүне кулланмыйча гына тормышка ашырыла.

1.4. Дәүләт хезмәтен күрсәтүне көйли торган норматив-хокукый актлар исемлеге (норматив-хокукый актларның реквизитларын һәм рәсми бастырып чыгару чыганакларын күрсәткән хәлдә) Министрлыкның рәсми сайтында, «Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр реестры» дәүләт мәгълүмат системасында урнаштырылган.

1.5. Әлеге Регламентта түбәндәге терминнар һәм аларның билгеләмәләре кулланыла:

дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең күпфункцияле үзәге (алга таба – КФҮ) – 2010 елның 27 июленнән «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 210-ФЗ номерлы федераль закон таләпләренә җавап бирә торган дәүләт яки муниципаль учреждениесе оештыру-хокукый формасында төзелгән һәм «бер тәрәзә» принцибы буенча дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне, шул исәптән электрон формада да, оештыруга вәкаләтле оешма;

дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең күпфункцияле үзәгенең читтә урнашкан эш урыны – Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2012 елның 22 декабреннән «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең күпфункцияле үзәкләренең эшчәнлеген оештыру кагыйдәләрен раслау турында» 1376 нчы номерлы карары белән расланган Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең күпфункцияле үзәкләре эшчәнлеген оештыру кагыйдәсенең 34 нче пунктына туры китереп, Татарстан Республикасы муниципаль районының (шәһәр округының) шәһәр һәм авыл

җирлекләрендә булдырылган дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең күпфункцияле үзәгенең территориаль аерымлашкан структур бүлекчәсе (офисы);

техник хата – дәүләт хезмәте күрсәтә торган орган тарафыннан җибәрелгән һәм документка (дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе) кертелгән белешмәләрнең шулар нигезендә кертелгән мәгълүматларның документлардагы белешмәләргә туры килмәвенә китергән хата (язудагы хата, басмадагы хата, грамматик яки арифметик хата);

ББСК – Бердәм бөтенроссия спорт классификациясе;

СМК – «спорт мастерына кандидат» спорт разряды.

ИАБС – инфраструктурада идентификация һәм аутентификацияләүнең бердәм системасы, ул дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү өчен электрон формада кулланыла торган мәгълүмати системаларның үзара мәгълүмати-технологик хезмәттәшлеген тәэмин итә.

Әлеге Регламентта дәүләт хезмәте күрсәтү турында гариза (алга таба – гариза) дәүләт хезмәте күрсәтүне сорау (2010 елның 27 июленнән «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 210-ФЗ номерлы федераль законның (алга таба – 210-ФЗ номерлы федераль закон) 2 нче маддәсенең 1 нче пункты) дигәнне аңлата. Гаризаның тәкъдим ителә торган формалары әлеге Регламентның 1-4, 7, 8 нче кушымталарында бирелә.

## 2. Дәүләт хезмәте күрсәтүнең стандарты

| Дәүләт хезмәте күрсәтү стандартына таләп атамасы | Стандартка карата таләпләр эчтәлеге | Хезмәт күрсәтү яки таләпне билгеле торган норматив акт |
|---|---|---|
| 2.1. Дәүләт хезмәте атамасы | «Спорт мастерлыгына кандидат» һәм «беренче спорт разряды» спорт разрядларын, «беренче категорияле спорт хөкемдары» квалификация категориясен бирү, аннан мәхрүм итү, яңадан торгызу (алга таба – бирү, мәхрүм итү һәм яңадан торгызу) буенча һәм Россия Федерациясе Спорт министрлыгына спорт исемнәрен, «бөтенроссия категорияле спорт хөкемдары» квалификация категориясен бирү, мәхрүм итү һәм яңадан торгызу өчен тәкъдимнәр юллау (алга таба – тәкъдим) буенча дәүләт хезмәте күрсәтү | 329-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә физик культура һәм спорт турында» (алга таба – 329-ФЗ номерлы Федераль закон) федераль законның 22 маддәсе;<br>Россия Федерациясе Спорт министрлыгының 2017 елның 20 февраленнән «Бердәм бөтенроссия спорт классификациясе турында нигезләмәне раслау турында» (алга таба – ББСК) 108 нче номерлы боерыгы;<br>Россия Федерациясе Спорт министрлыгының 2017 елның 28 февраленнән « Спорт хөкемдарлары турында Нигезләмәне раслау |

| | | |
|---|---|---|
| | | турында» (алга таба – Спорт хөкемдарлары турында нигезләмә) 134 нче номерлы боерыгы |
| 2.2. Башкарма хакимият органы атамасы | Татарстан Республикасы Спорт Министрлыгы (алга таба – Министрлык) | Татарстан Республикасының 2008 елның 8 октябеннән «Физик культура һәм спорт турында» 99-ЗРТ номерлы Законы; Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2005 елның 6 июненнән 315 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Спорт министрлыгы турында нигезләмә |
| 2.3. Дәүләт хезмәте күрсәтүнең нәтиҗәсен сурәтләү | 1. Бирелгән разряд (категория) турында билге белән билгеләнгән спортчы яки хөкемдар зачет квалификация китапчыгын (билгеләнгән разряд (категория) значогы белән) бирү, «спорт мастерлыгына кандидат» яки «беренче спорт разряды» разрядларыннан, «беренче категорияле спорт хөкемдары» квалификацияле | ББСК Нигезләмәсенең 45, $45^2$, 65 пунктлары; Спорт хөкемдарлары турындагы Нигезләмәнең 27, 28, 52 пунктлары |

| | | |
|---|---|---|
| | категориясеннән мәхрүм иткәндә боерыкның расланган күчермәсен бирү.<br>2. Разряд яки категорияне бирү, мәхрүм итү, яңадан торгызудан баш тарту турында хат.<br>3. Россия Федерациясе Спорт министрлыгына спорт исемнәрен, «бөтенроссия категорияле спорт хөкемдары» квалификация категориясен бирү, мәхрүм итү һәм яңадан торгызу өчен тәкъдим юллау.<br>4. Россия Федерациясе Спорт министрлыгына исем, категориясен бир буенча тәкъдим юллаудан баш тарту турында хат | |
| 2.4. Дәүләт хезмәте күрсәтү вакыты, шул исәптән дәүләт хезмәтен күрсәтүдә катнаша торган оешмаларга мөрәҗәгать итү кирәклеген истә тотып; әгәр Россия Федерациясе законнарында туктатып тору мөмкинлеге каралган булса, дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып тору вакыты, дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе булып торган документларны бирү (җибәрү) вакыты | «Спорт мастерлыгына кандидат» һәм «беренче спорт разряды» разрядларын, «беренче категорияле спорт хөкемдары» спорт хөкемдары квалификация категориясен бирү, мәхрүм итү һәм яңадан торгызу документлар комплекты белән гаризаны теркәгәннән соң биш эш көне эчендә тормышка ашырыла.<br>Россия Федерациясе Спорт министрлыгына тәкъдимнәр юллау документларның билгеләнгән комплекты белән гаризаны теркәгәннән соң биш эш көне эчендә тормышка ашырыла.<br>Дәүләт хезмәте нәтиҗәсе булып торган документ гариза бирүче мөрәҗәгать иткән көнне | |

| | | |
|---|---|---|
| | бирелә.<br>Дәүләт хезмәте нәтиҗәсе булып торган документны гаризада күрсәтелгән элемтә ысулын кулланып (почта яки электрон адреска) җибәрү дәүләт хезмәте нәтиҗәсен рәсмиләштерү һәм теркәү көнендә гамәлгә ашырыла.<br>Дәүләт хезмәте күрсәтү вакытын туктатып тору каралмаган. | |
| 2.5. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен законнар һәм башка норматив хокукый актлар белән каралган, шулай ук дәүләт хезмәте күрсәтү өчен зарур һәм мәҗбүри булган хезмәтләр өчен Гариза бирүче тәкъдим итәргә тиешле мәҗбүри документларның тулы исемлеге, гариза бирүче тарафыннан, шул исәптән электрон формада да, аларны алу ысуллары, аларны бирү тәртибе. | 1. «Спорт мастерлыгына кандидат» һәм «беренче спорт разряды» спорт разрядларын бирү өчен түбәндәге документларны тәкъдим итәргә кирәк:<br>гариза (3 нче кушымта);<br>түбәндәге документлар комплекты белән тәкъдим итү (5 нче кушымта):<br>а) нормалар һәм таләпләр үтәлешен һәм аларны үтәүнең шартларын чагылдыра торган ярышның баш хөкемдарлары коллегиясе рәисе (баш хөкемдары) имзалаган беркетмә күчермәсе яки беркетмәдән өземтә – барлык спорт разрядларын бирү өчен;<br>б) хөкемдарлар коллегиясе составы һәм квалификациясе турында:<br>«спорт мастерлыгына кандидат», «беренче спорт разряды», «икенче спорт разряды», «өченче | ББСК Нигезләмәсенең 50 пункты;<br>Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2016 елның 26 мартыннан «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләрен электрон формада күрсәтүгә таләпләр турында» 236 номерлы карары (алга таба – 236 номерлы карар) |

| | | |
|---|---|---|
| | спорт разряды» спорт разрядларын бирү өчен (халыкара ярышлардан тыш) – хөкемдарлар коллегиясе рәисе (баш хөкемдар) һәм ярышлар уздыра торган оешманың вәкаләтле заты тарафыннан;<br>яшүсмерләр спорт разрядлары бирү өчен – хөкемдарлар коллегиясе рәисе (баш хөкемдар) тарафыннан имзаланган белешмә күчермәсе:<br>в) 3х4 см зурлыгындагы ике фотосурәт;<br>г) спортчының физик культура-спорт федерациясенә, спорт хәзерлеген тормышка ашыра торган оешмага яисә белем бирү оешмасына керүе (региональ спорт федерациясенең дәүләт аккредитациясенең гамәлдә булуы туктатылган очракта) турында документ күчермәсе;<br>д) Россия Федерациясе гражданины паспортының икенче һәм өченче битләренең, шулай ук тору урыны турында мәгълүматлар булган битләренең күчермәләре, ул булмаганда – Россия Федерациясе территориясе чикләрендә Россия Федерациясе гражданы шәхесен раслый торган Россия Федерациясе гражданы паспортының фамилиясе, исеме, атасының исеме (булган очракта), документ биргән орган, документның гамәлдә булу вакыты тәмамлану | |

| | | |
|---|---|---|
| | датасы турында мәгълүматлар булган битләренең күчермәләре (яшүсмерләр спорт разрядларыннан тыш).<br>14 яшькә җитмәгән затлар өчен – чил дәүләтнең компетент органнары тарафыннан бирелгән туу турында таныклык күчермәсе һәм аның нотариаль рәвештә расланган рус теленә тәрҗемәсе (чит дәүләт территориясендә туган очракта);<br>Чакырылыш буенча хәрби хезмәт үтүче хәрби хезмәткәрләр өчен Россия Федерациясе гражданы паспортының күрсәтелгән битләре күчермәләре урынына хәрби билет күчермәсе бирелергә мөмкин;<br>е) спорт разрядын бирү өчен спортчы нормаларны, таләпләрне һәм аларны үтәү шартларын үтәгән физкультура чарасы һәм (яки) хәрби-гамәли һәм хезмәт-гамәли спорт төрләре буенча спорт ярышларында турында нигезләмә (регламент) күчермәсе (спортның хәрби-гамәли һәм хезмәт-гамәли төрләре өчен);<br>ж) тиешле ярышларда катнашкан илләр (халыкара ярышлар өчен) яки Россия Федерациясе субъектлары (бөтенроссия һәм төбәкара ярышлар өчен) саны турында мәгълүматларны үз эченә алган ярышларның | |

| | | |
|---|---|---|
| | баш хөкемдарлар коллегиясе рәисе (баш хөкемдар) тарафыннан имзаланган документ (белешмә, беркетмә) күчермәсе.<br>2. «Беренче категорияле спорт хөкемдары» квалификация категориясен бирү өчен түбәндәге документларны тәкъдим итәргә кирәк:<br>гариза (4 нче кушымта);<br>түбәндәге документлар комплекты белән тәкъдим (тәкъдим ителә торган форма Спорт хөкемдарлары турында нигезләмәнең 1 нче кушымтасында китерелә):<br>а) мөһер (булган очракта) һәм региональ спорт федерациясе, федераль орган бүлекчәсе җитәкчесе яисә вазыйфаи заты имзасы белән расланган исәп карточкасы күчермәсе;<br>б) Россия Федерациясе гражданины паспортының икенче һәм өченче битләренең, шулай ук кандидатның тору урыны турында мәгълүматлар булган битләренең күчермәләре, ул булмаганда – Россия Федерациясе территориясе чикләрендә Россия Федерациясе гражданы шәхесен раслый торган Россия Федерациясе гражданы паспортының фамилия, исеме, атасының исеме (булган очракта), документ биргән орган, документның гамәлдә булу вакыты тәмамлану датасы турында | Спорт хөкемдарлары турында нигезләмәнең 29 пункты |

| | | |
|---|---|---|
| | мәгълүматлар булган битләренең күчермәләре – Россия Федерациясе гражданнары өчен;<br>в) чит ил гражданы паспорты яисә 2002 елның 25 июленнән «Россия Федерациясендә гражданнарның хокукый хәле турында» 115-ФЗ номерлы Федераль закон белән билгеләнгән башка документ күчермәсе (алга таба – 115-ФЗ номерлы Федераль закон) (Россия Федерациясе законнары җыентыгы, 2002, № 30, 3032 маддә; 2019, № 30, № 4134 маддә) яисә чит ил гражданы шәхесен раслаучы документ буларак Россия Федерациясенең халыкара шартнамәсе нигезендә чит ил гражданы буларак танылa торган башка документ күчермәсе – чит ил гражданнары өчен;<br>г) Россия Федерациясендә гражданлыгы булмаган затның шәхесен раслаучы чит ил дәүләте тарафыннан бирелгән һәм Россия Федерациясенең халыкара шартнамәсе нигезендә гражданлыгы булмаган зат шәхесен таныклый торган документ буларак танылучы документ күчермәсе яисә 115-ФЗ номерлы Федераль закон белән каралган яисә Россия Федерациясенең халыкара шартнамәсе нигезендә гражданлыгы булмаган зат шәхесен раслаучы документ буларак танылучы башка | |

| | | |
|---|---|---|
| | документ күчермәсе – гражданлыгы булмаган затлар өчен;<br>д) хәрби билет күчермәсе – чакырылыш буенча хезмәт уза торган хәрби хезмәткәрләр өчен ( Россия Федерациясе гражданы паспорты булмаган очракта);<br>е) «Халыкара класслы Россия спорт мастеры», «Россия гроссмейстеры» яки «Россия спорт мастеры» таныклыклары күчермәсе – квалификация категориясен бирү Спорт хөкемдарлары турында нигезләмәнең 25, 26 нчы пунктларының өченче кызыл юлы нигезендә башкарылган кандидатлар өчен;<br>ж) 3 х 4 см зурлыгындагы 2 фотосурәт.<br>3. Россия Федерациясе Спорт министрлыгына спорт исемнәрен бирү өчен тәкъдимнәр юллау өчен түбәндәге документларны тәкъдим итәргә кирәк:<br>гариза (1 нче кушымта);<br>түбәндәге документлар комплекты белән тәкъдим (5 нче кушымта):<br>а) нормалар һәм таләпләр һәм аларны үтәү шартларының үтәлешен чагылдыра торган, ярышның баш хөкемдарлары коллегиясе рәисе (баш хөкемдары) имзалаган беркетмә күчермәсе яки беркетмәдән өземтә; | ББСК Нигезләмәсенең 33 пункты |

| | | |
|---|---|---|
| | б) хөкемдарлар коллегиясе составы һәм квалификациясе турында ярышның баш хөкемдарлар коллегиясе рәисе (баш хөкемдары) имзалаган белешмә күчермәсе (халыкара ярышлардан тыш);<br>в) «Бөтенроссия категорияле спорт хөкемдары» таныклыклары күчермәләре (спортчы норма, таләпләр һәм шартларны үтәгән ярышларда хөкемдарлык иткән хөкемдарлар коллегиясенә керелгән 3 тән дә ким булмаган спорт хөкемдарының таныклыклары күчермәләре тәкъдим ителә);<br>г) 3х4 см зурлыгындагы ике фотосурәт;<br>д) спортчының физик культура-спорт федерациясенә, спорт хәзерлеген тормышка ашыра торган оешмага яисә белем бирү оешмасына керүе (региональ спорт федерациясенең дәүләт аккредитациясенең гамәлдә булуы туктатылган очракта) турында документ күчермәсе;<br>е) Башкарма хакимият органының региональ спорт федерациясенең дәүләт аккредитациясенең гамәлдә булуын туктату турында документы күчермәсе (региональ спорт федерациясенең дәүләт аккредитациясенең гамәлдә булуы туктатылган очракта); | |

| | | |
|---|---|---|
| | ж) Россия Федерациясе гражданины паспортының икенче һәм өченче битләренең, шулай ук тору урыны турында мәгълүматлар булган битләренең күчермәләре, ул булмаганда - Россия Федерациясе территориясе чикләрендә Россия Федерациясе гражданы шәхесен раслый торган Россия Федерациясе гражданины паспортының фамилиясе, исеме, атасының исеме (булган очракта), документ биргән орган, документның гамәлдә булу вакыты тәмамлану датасы турында мәгълүматлар булган битләренең күчермәләре.<br>з) спортчының спорт исеме бирү өчен нормаларны, таләпләрне һәм шартларны үтәгән спортның хәрби-гамәли һәм хезмәт-гамәли төрләре буенча физкультура чарасы һәм (яки) спорт ярышлары турында нигезләмә (регламент) күчермәсе (спортның хәрби-гамәли һәм хезмәт-гамәли төрләре өчен);<br>и) туры килә торган ярышларда катнашучы илләр (халыкара ярышлар өчен) яки Россия Федерациясе субъектлары (бөтенроссия һәм төбәкара ярышлар өчен) саны турында мәгълүматлар булган ярышларның баш хөкемдарлары коллегиясе рәисе (баш хөкемдары) тарафыннан имзаланган документ | |

| | | |
|---|---|---|
| | (белешмә, беркетмә) күчермәсе..<br>14 яше тулмаган затлар өчен – туу турында таныклык күчермәсе.<br>Чакырылыш буенча хәрби хезмәт үтүче хәрби хезмәткәрләр өчен Россия Федерациясе гражданы паспортының күрсәтелгән битләре күчермәләре урынына хәрби билет күчермәсе бирелергә мөмкин. | |
| | 4. Россия Федерациясе Спорт министрлыгына «Бөтенроссия категорияле спорт хөкемдары» квалификация категориясен бирү өчен тәкъдимнәр юллау өчен түбәндәге документларны бирергә кирәк:<br>гариза (2 нче кушымта);<br>түбәндәге документлар комплекты белән тәкъдим (тәкъдим ителә торган үрнәк Спорт хөкемдарлары турындагы нигезләмәнең 1 нче кушымтасында бирелә):<br>а) мөһер (булган очракта) һәм региональ спорт федерациясе яки федераль орган бүлекчәсе җитәкчесе имзасы белән расланган спорт хөкемдарының хөкемдарлык эшчәнлеген исәпкә алу карточкасы күчермәсе (тәкъдим ителә торган форма Спорт хөкемдарлары турындагы нигезләмәнең 2 нче кушымтасында китерелә) (алга таба – исәпкә алу карточкасы); | Спорт хөкемдарлары турында нигезләмәнең 8 пункты |

| | | |
|---|---|---|
| | б) Россия Федерациясе гражданины паспортының икенче һәм өченче битләренең, шулай ук тору урыны турында мәгълүматлар булган битләренең күчермәләре, ул булмаганда - Россия Федерациясе территориясе чикләрендә Россия Федерациясе гражданы шәхесен раслый торган Россия Федерациясе гражданы паспортының фамилиясе, исеме, атасының исеме (булган очракта), документ биргән орган, документның гамәлдә булу вакыты тәмамлану датасы турында мәгълүматлар булган битләренең күчермәләре;<br>в) чит ил гражданы паспорты яисә 2002 елның 25 июленнән «Россия Федерациясендә гражданнарның хокукый хәле турында» 115-ФЗ номерлы Федераль закон белән билгеләнгән башка документ күчермәсе (алга таба – 115-ФЗ номерлы Федераль закон) (Россия Федерациясе законнары җыентыгы, 2002, № 30, 3032маддә; 2019, № 30, № 4134 маддә) яисә чит ил гражданы шәхесен раслаучы документ буларак Россия Федерациясенең халыкара шартнамәсе нигезендә чит ил гражданы буларак танылa торган башка документ күчермәсе – чит ил гражданнары өчен;<br>г) Россия Федерациясендә гражданлыгы | |

| | | |
|---|---|---|
| | булмаган затның шәхесен раслаучы чит ил дәүләте тарафыннан бирелгән һәм Россия Федерациясенең халыкара шартнамәсе нигезендә гражданлыгы булмаган зат шәхесен таныклаучы документ буларак танылучы документ күчермәсе яисә 115-ФЗ номерлы Федераль закон белән каралган яисә Россия Федерациясенең халыкара шартнамәсе нигезендә гражданлыгы булмаган зат шәхесен раслаучы документ буларак танылучы башка документ күчермәсе – гражданлыгы булмаган затлар өчен;<br>д) хәрби билет күчермәсе – чакырылыш буенча хезмәт уза торган хәрби хезмәткәрләр өчен ( Россия Федерациясе гражданы паспорты булмаган очракта);<br>е) «Республика категориясендәге спорт буенча хөкемдар» яки «Бөтенроссия категорияле спорт категориясе буенча хөкемдар» таныклыгы күчермәсе яки спорт хөкемдарының тиешле категориясен бирүне раслый торган документ күчермәсе яки архив белешмәсе күчермәсе – квалификация категориясен бирү Нигезләмәнең 5 нче пунктының өченче кызыл юлы нигезендә башкарылган кандидатлар өчен;<br>ж) 3 х 4 см зурлыгындагы 2 фотосурәт. | |

| | | |
|---|---|---|
| | 5. Спорт разрядлары һәм исемнәреннән мәхрүм итү һәм аларны яңадан торгызу өчен 7 нче кушымта буенча Гариза бирергә кирәк, анда түбәндәгеләр булырга тиеш:<br>а) аңа карата спорт разряды, исеме, квалификация категориясеннән мәхрүм итү яки аларны яңадан торгызу турында гариза бирелгән спортчының фамилиясе, исеме һәм атасының исеме (булган очракта), туу датасы;<br>б) спорт разряды, исеме, квалификация категориясен биргән яисә аннан мәхрүм иткән оешма документының датасы һәм номеры;<br>в) спорт разрядын, исемен, квалификация категориясеннән мәхрүм итү яки яңадан торгызу өчен нигезне дәлилли торган белешмәләр (мәхрүм итү яки яңадан торгызу өчен нигезләрне дәлилли торган документларны теркәп).<br>6. Спорт хөкемдарлык квалификация категорияләреннән мәхрүм итү яки яңадан торгызу өчен 8 нче кушымта буенча гариза бирергә кирәк, анда түбәндәгеләр булырга тиеш:<br>а) аңа карата квалификация категориясеннән мәхрүм итү яки яңадан торгызу турында гариза бирелгән спорт хөкемдарының фамилиясе, исеме, атасының исеме (булган очракта), туу датасы; | ББСК Нигезләмәсенең 85, 94 пунктлары<br><br>Спорт хөкемдарлары турында нигезләмәнең 50, 59, 69, 78 пунктлары |

| | | |
|---|---|---|
| | б) оешманың квалификация категориясен бирү яки мәхрүм итү турында документының датасы һәм номеры;<br>в) квалификация категориясеннән мәхрүм итү яки яңадан торгызу өчен нигезне дәлилли торган белешмәләр (мәхрүм итү яки яңадан торгызу өчен нигезләрне дәлилли торган документларны теркәп).<br>Дәүләт хезмәте алу өчен гариза бланкын гариза бирүче Министрлыкка шәхси мөрәҗәгать иткәндә алырга мөмкин. Бланкның электрон формасы Министрлыкның рәсми сайтында урнаштырылган.<br>Гариза һәм теркәлә торган документлар түбәндәге ысулларның берсе ярдәмендә:<br>шәхсән (ышаныч кәгазе нигезендә гариза бирүче исеменнән эш итүче зат тарафыннан);<br>почта аша кәгазьдә гариза бирүче тарафыннан бирелергә (юлланырга) мөмкин;<br>2011 елның 6 апреленнән «Электрон имза турында» 63-ФЗ номерлы федераль закон (алга таба – 63-ФЗ номерлы федераль закон) һәм 210-ФЗ номерлы федераль закон таләпләре нигезендә, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәре аша һәм Татарстан Республикасы Дәүләт һәм муниципаль | |

| | | |
|---|---|---|
| | хезмәтләр порталы аша электрон имза белән имзаланган электрон документ рәвешендә электрон формада. | |
| 2.6. Дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары һәм башка оешмалар карамагында булган дәүләт хезмәте күрсәтү өчен норматив хокукый актлар нигезендә кирәк булган һәм гариза бирүче бирергә хокуклы булган документларның тулы исемлеге, шулай ук гариза бирүчеләрнең аларны алу ысуллары, шул исәптән электрон рәвештә дә, аларны бирү тәртибе; әлеге документлар алар карамагында булган дәүләт органы, җирле үзидарә органы яисә оешма | Ведомствоара хезмәттәшлек кысаларында алына:<br>14 яше тулмаган затлар өчен – туу турында мәгълүмат.<br>Гариза бирүчедән түбәндәгеләрне таләп итү тыела:<br>дәүләт хезмәтен күрсәтүгә бәйле рәвештә барлыкка килә торган мөнәсәбәтләрне җайга сала торган норматив хокукый актларда тапшыру яисә аларны гамәлгә ашыру каралмаган гамәлләрне гамәлгә ашыру өчен документлар һәм мәгълүмат бирү;<br>Россия Федерациясе норматив хокукый актлары, Татарстан Республикасы норматив хокукый актлары нигезендә дәүләт хезмәте күрсәтүче дәүләт органнары, башка дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары һәм (яисә) дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнашучы оешмалар карамагында булган дәүләт һәм муниципаль хезмәт күрсәтүләр өчен түләү кертүне раслаучы документлар һәм мәгълүмат, шул исәптән, 210-ФЗ номерлы Федераль закондагы 7 маддәнең 6 нчы өлешендә күрсәтелгән документлардан | |

| | | |
|---|---|---|
| | тыш;<br>210-ФЗ номерлы Федераль закондагы 7 нче маддәнең 1 нче өлешендәге 4 нче пунктта каралган очраклардан тыш, дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларны беренчел кабул итүдән баш тартканда яисә дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тартканда аларның булмавы һәм (яисә) дөреслеге күрсәтелмәгән документлар һәм мәгълүмат бирү;<br>электрон рәвешләре 210-ФЗ номерлы Федераль законның 16 нчы маддәсендәге 1нче өлешенең 72 нче пункты нигезендә элек расланган документлар һәм мәгълүматны кәгазьдә бирү, мондый документларга тамга кую яисә аларны алудан тыш, дәүләт яки муниципаль хезмәт күрсәтүнең һәм федераль законнарда билгеләнгән башка очракларның кирәкле шарты булып тора. | |
| 2.7. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен мәҗбүри булган документларны кабул итүдән баш тарту өчен сәбәпләрнең тулы исемлеге | Гариза кабул итүдән баш тарту өчен сәбәп булып Регламентның 2.5 пунктында күрсәтелгән документлар (тулы булмаган) комплекты бирелмәү тора. | |
| 2.8. Дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып тору яисә аңардан баш тарту өчен сәбәпләрнең тулы исемлеге | Дәүләт хезмәтен күрсәтүдән баш тарту өчен нигезләмәләр:<br>«Спорт мастерлыгына кандидат» һәм «беренче разряд» спорт разрядларын бирүдән баш тарту | |

| | | |
|---|---|---|
| | өчен түбәндәгеләр нигез булып тора:<br>- спортчы нәтиҗәсенең спорт разрядын бирү өчен Министрлык тарафыннан расланган документларда күрсәтелгән нормаларга, таләпләргә һәм аларны үтәү шартларына туры килмәве;<br>- спортчының норма, таләп һәм аларны үтәү шартларын үтәгән ярыш көненә кадәр яисә узган көндә булган спорт дисквалификациясе;<br>- ярышлар һәм (яки) физкультура чаралары турындагы нигезләмәләрдә (регламентларда) билгеләнгән оештыручылар тарафыннан расланган ярышларга һәм (яки) физкультура чараларына керү шартларын бозу;<br>«Спорт мастерлыгына кандидат» һәм «беренче разряд» спорт разрядларыннан мәхрүм итүдән баш тартуның нигезләре булып түбәндәгеләр тора:<br>- тапшырылган белешмәләрнең ББСК Нигезләмәсенең 83нче пунктында каралган спорт разрядыннан мәхрүм итү өчен нигезләргә туры килмәве;<br>- спорт федерациясе, физкультура-спорт оешмасы, спорт әзерлеген гамәлгә ашыручы оешма, белем бирү оешмасы яки Гариза бирүче тарафыннан элек бирелгән спорт разрядыннан | |

| | | |
|---|---|---|
| | мәхрүм итү турында гариза буенча оешма карары булу.<br>«Спорт мастерлыгына кандидат» һәм «беренче разряд» спорт разрядын торгызудан баш тарту өчен нигез булып түбәндәгеләр тора:<br>- тапшырылган белешмәләрнең ББСК Нигезләмәсенең 92нче пунктының икенче абзацы белән каралган спорт разрядыннан торгызу өчен нигезләргә туры килмәве;<br>- спорт федерациясе, физкультура-спорт оешмасы, спорт әзерлеген гамәлгә ашыручы оешма, белем бирү оешмасы, Гариза бирүче яки спортчы тарафыннан спорт разрядын торгызу турында элек бирелгән гариза буенча Оешма карары булу.<br>Россия Федерациясе Спорт министрлыгы тарафыннан расланган Квалификация таләпләрен үтәмәү (спорт төрләре буенча) «беренче категорияле спорт судьясы» квалификация категориясен бирүдән баш тарту өчен нигез булып тора.<br>«Беренче категорияле спорт судьясы» квалификация категориясеннән мәхрүм итүдән баш тарту өчен бирелгән белешмәләрнең спорт судьялары турындагы Нигезләмәнең 67 нче пунктында каралган квалификация | |

| | | |
|---|---|---|
| | категориясеннән мәхрүм итү өчен нигезләргә туры килмәве нигез булып тора.<br>«Беренче категорияле спорт судьясы» квалификация категориясен торгызудан баш тарту өчен түбәндәгеләр нигез булып тора:<br>- тапшырылган белешмәләрнең спорт судьялары турындагы Нигезләмәнең 76 нчы пунктында каралган квалификация категориясен торгызу өчен нигезгә туры килмәве;<br>- региональ спорт федерациясе яки спорт судьясы тарафыннан квалификация категориясен торгызу турында элек бирелгән гариза буенча оешма карары булу.<br>«Бөтенроссия категориясендәге спорт судьясы» квалификация категориясен бирү, мәхрүм итү, яңадан торгызу өчен Россия Федерациясе Спорт министрлыгына юллаудан баш тарту өчен әлеге Регламентның 2.5 нче пунктындагы 4 нче пунктчасында күрсәтелгән документларның тулы комплекты булмау нигез булып тора. | |
| 2.9. Дәүләт хезмәте күрсәткән өчен алына торган дәүләт пошлинасы яки башка төр түләүнең тәртибе, күләме һәм алу өчен сәбәпләр | Дәүләт хезмәте бушлай нигездә күрсәтелә. | |
| 2.10. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле һәм мәҗбүри булган | Кирәкле һәм мәҗбүри булган хезмәтләр күрсәтү таләп ителми. | |

| | | |
|---|---|---|
| хезмәтләр исемлеге, шул исәптән дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнашучы оешмалар тарафыннан бирелә торган документ (документлар) турында белешмәләр | | |
| 2.11. Мондый түләү күләмен исәпләү методикасы турындагы мәгълүматны да кертеп, дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен кирәкле һәм мәҗбүри булган хезмәтләр күрсәткән өчен түләү алу тәртибе, күләме һәм нигезләре | Кирәкле һәм мәҗбүри булган хезмәтләр күрсәтү таләп ителми. | |
| 2.12. Дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнаша торган оешма күрсәтә торган дәүләт хезмәте күрсәтү турында запрос биргән вакытта һәм шундый хезмәтләр күрсәтүнең нәтиҗәсен алганда чиратта көтүнең максималь вакыты | Дәүләт хезмәте күрсәтү турында запрос биргәндә һәм шундый хезмәтләр күрсәтүнең нәтиҗәсен алганда чиратта көтүнең максималь вакыты 15 минуттан артмаска тиеш.<br>Дәүләт хезмәте алучыларның аерым категорияләре өчен чират билгеләнмәгән. | Россия Федерациясе Президентының «Дәүләт идарәсе системасын камилләштерүнең төп юнәлешләре турында» 601 нче Указының 1 нче подпункты |
| 2.13. Гариза бирүченең дәүләт хезмәте күрсәтүне һәм дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнаша торган оешма күрсәтә торган хезмәт күрсәтүне сорап, шул исәптән электрон формада да, гаризасын | Гариза кергән көндә.<br>Ял (бәйрәм) көнендә электрон формада кергән мөрәҗәгать ял (бәйрәм) көненнән соң килгән эш көнендә теркәлә.<br>Татарстан Республикасы Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталына (техник | |

| | | |
|---|---|---|
| (запрос) теркәү вакыты һәм тәртибе | мөмкинлек булганда) электрон рәвештә кергән гариза, региональ порталда мөрәҗәгатьләрне автомат рәвештә теркәү булмаган очракта, Министрлык тарафыннан билгеләнгән тәртиптә теркәлә. | |
| 2.14. Дәүләт хезмәте күрсәтелә торган биналарга, көтү залына, дәүләт хезмәте күрсәтү турында гаризалар тутыру өчен урыннарга, аларны тутыру үрнәкләре һәм дәүләт хезмәте күрсәтү өчен мәҗбүри булган документларның тулы исемлеге белән мәгълүмати стендларга, шундый хезмәтләр күрсәтү тәртибе турында визуаль, текстлы һәм мультимедияле мәгълүматны урнаштыру һәм бизәүгә карата, шул исәптән Россия һәм Татарстан Республикасының инвалидларны социаль яклау турындагы законнары нигезендә күрсәтелгән объектларның инвалидлар өчен файдалана алырлык булуларын тәэмин итүгә таләпләр | Дәүләт хезмәтен күрсәтү янгынга каршы система һәм янгын сүндерү системасы, документларны рәсмиләштерү өчен кирәкле мебель, мәгълүмат стендлары белән җиһазландырылган Министрлык бинасында һәм бүлмәләрендә тормышка ашырыла.<br>Дәүләт хезмәте күрсәтү тәртибе турында визуаль, текст һәм мультимедиа мәгълүматы гариза бирүчеләр өчен уңайлы урыннарда, шул исәптән инвалидларның чикләнгән мөмкинлекләрен исәпкә алып урнаштырыла.<br>Инвалидларның (кресло-коляскалар һәм озатып йөрүче этләрне дә кертеп) дәүләт хезмәте күрсәтү урынына тоткарлыксыз керә алуын оештыру максатларында аларга дәүләт хезмәте күрсәтү буенча түбәндәгеләр тәэмин ителә:<br>бинага һәм биналарга, шулай ук аларда күрсәтелә торган хезмәтләргә тоткарлыксыз керү шартлары;<br>хезмәт күрсәтүче хезмәткәрләр ярдәме белән яисә мөстәкыйль рәвештә Министрлык | 1995 елның 24 ноябреннән «Россия Федерациясендә инвалидларны социаль яклау турында» 181-ФЗ федераль закон;<br>ТР МК ның 2010 елның 2 ноябреннән 880 нче номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнары белән дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентларын эшләү һәм раслау тәртибе (алга таба - ТР МК ның 2010 елның 2 ноябреннән 880 нче номерлы карары белән расланган Тәртип) |

| | | |
|---|---|---|
| | территориясе буйлап хәрәкәт итү, бина һәм бүлмәгә керү һәм чыгу мөмкинлеге:<br>транспорт чарасына утырту һәм аннан бинага керү алдыннан, шул исәптән кресло-коляска кулланып һәм кирәк булганда, хезмәт күрсәтүче хезмәткәрләр ярдәме белән төшерү мөмкинлеге;<br>күрү сәләте һәм мөстәкыйль хәрәкәт функциясе бозылуга ия инвалидларны озатып бару һәм аларга бинада һәм биналарда ярдәм күрсәтү;<br>инвалидларның мөмкинлекләре чикле булуны исәпкә алган хәлдә объектларга һәм хезмәт күрсәтүләргә тоткарлыксыз үтеп керүен тәэмин итү өчен кирәкле җиһазларны һәм мәгълүмат йөртүчеләрне тиешле рәвештә урнаштыру;<br>инвалидлар өчен кирәкле тавыш һәм күрү мәгълүматын, шулай ук язуларны, билгеләрне һәм башка текст һәм график мәгълүматны Брайльнең рельеф-нокталы шрифты белән башкарылган билгеләр белән кабатлау, сурдотәрҗемәче һәм тифлосурдотәрҗемәчегә мөрәҗәгать итү мөмкинлеге бирү;<br>бинага, махсус укыту узуын раслаучы документ булганда, озатып йөрүче этне кертү;<br>хезмәт күрсәтүче хезмәткәрләргә, хезмәт күрсәтүче инвалидларга башка затлар белән беррәттән хезмәт күрсәтүгә һәм объектлардан | |

| | | |
|---|---|---|
| | файдалануга комачаулаучы киртәләрне җиңеп чыгуда башка төр кирәкле ярдәм күрсәтү;<br>бинаны инвалидлар физик культура һәм спорт белән шөгыльләнү өчен, алар организмындагы функцияләрнең нык бозылуларын һәм тормыш эшчәнлегендәге чикләүләрне исәпкә алып, махсус спорт инвентаре һәм җиһазлар белән тәэмин итү;<br>инвалидларга, тормыш эшчәнлеге чикләүләрен исәпкә алып, махсуслаштырылган төркемнәрдә физик культура һәм спорт белән шөгыльләнү өчен шартлар тудыру;<br>инвалидлар белән физик культура һәм спорт дәресләрен үткәрү өчен әзерләнгән хезмәткәрләр булу.<br>Инвалидлар өчен дәүләт хезмәте күрсәтелә торган объектларның үтемлелеген тәэмин итү өлешендә таләпләр 2016 елның 1 июленнән соң файдалануга тапшырылган, капиталь ремонт, реконструкция, модернизация узган объектларга карата кулланыла. | |
| 2.15. Дәүләт хезмәтенең һәркем файдалана алырлык булуы һәм сыйфаты күрсәткечләре, шул исәптән гариза бирүченең дәүләт хезмәте күрсәтелгән вакытта | Дәүләт хезмәте күрсәтүнең һәркем файдалана алырлык булу күрсәткечләре булып түбәндәгеләр тора:<br>бүлек бинасының җәмәгать транспортыннан файдалана алырлык зонада урнашуы; | Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 880 нче номерлы карары белән расланган Тәртипнең 2.4 пункты |

| | | |
|---|---|---|
| вазыйфаи затлар белән үзара тәэсир итешүе һәм аларның дәвамлылыгы, дәүләт хезмәте күрсәтүнең барышы турында, шул исәптән мәгълүмати-телекоммуникацион технологияләрне дә файдаланып, мәгълүмат алу мөмкинлеге, мөрәҗәгать итүче сайлавы буенча (экстерриториаль принцип) 210-ФЗ номерлы Федераль законның 151 маддәсендә каралган дәүләт һәм муниципаль хезмәт күрсәтүләрнең күпфункцияле үзәкләрендә берничә дәүләт һәм муниципаль хезмәт күрсәтүне сорау юлы белән дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең күпфункцияле үзәгендә (шул исәптән тулы күләмдә), башкарма хакимият органының теләсә кайсы территориаль бүлекчәсендә дәүләт хезмәте күрсәтүен алу мөмкинлегенең булуы яисә булмавы | белгечләрнең, шулай ук гариза бирүчеләрдән документларны кабул итә торган бүлмәләрнең кирәкле санда булуы;<br>дәүләт хезмәте күрсәтү ысуллары, тәртибе һәм вакыты турында мәгълүмати стендларда, «Интернет» челтәрендә, Министрлыкның рәсми сайтында тулы мәгълүмат булуы;<br>башка затлар белән бер үк дәрәҗәдә хезмәт алуга комачаулый торган киртәләрне узуда инвалидларга ярдәм күрсәтү.<br>Дәүләт хезмәте күрсәтүнең сыйфатын түбәндәгеләр характерлый:<br>гариза бирүчеләрдән гаризаларны кабул итү һәм аларга документлар бирү вакытында чиратлар булмау;<br>дәүләт хезмәте күрсәтү вакытын бозу булмау;<br>дәүләт хезмәте күрсәтә торган дәүләт хезмәткәрләренең гамәлләренә (гамәл кылмауларына) шикаятьләр булмау;<br>дәүләт хезмәте күрсәтә торган дәүләт хезмәткәрләренең гариза бирүчеләргә карата әдәпсез, игътибарсыз мөнәсәбәтенә шикаятьләр булмау.<br>Дәүләт хезмәте күрсәтү турында сорау (запрос) биргәндә һәм дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен алганда дәүләт хезмәте күрсәтүче вазыйфаи | |

| | | |
|---|---|---|
| | затның һәм мөрәҗәгать итүченең бер тапкыр үзара тәэсир итешүе күздә тотыла. Үзара тәэсир итешү дәвамлылыгы административ регламент белән билгеләнә.<br>Дәүләт хезмәте күрсәтүнең барышы турында мәгълүматны гариза бирүче minsport.tatarstan.ru сайтында, Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләрнең бердәм порталында, КФҮтә алырга мөмкин.<br>Дәүләт хезмәте экстерриториаль принцип буенча һәм комплекслы сорау (запрос) составында күрсәтелми.<br>Дәүләт хезмәте КФҮтә, КФҮнең читтәге эш урынында күрсәтелми. | |
| 2.16. Электрон формада муниципаль хезмәт күрсәтүнең үзенчәлекләре, шул исәптән экстериториаль принцип буенча муниципаль хезмәт күрсәтү үзенчәлекләрен исәпкә алучы (муниципаль хезмәт экстерриториаль принцип буенча бирелгән очракта) башка таләпләр | Хезмәт алу өчен гомумкулланыштагы мәгълүмати-телекоммуникацион челтәрләр, шул исәптән «Интернет» мәгълүмати-телекоммуникацион челтәрләр, һәм Татарстан Республикасы Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталы аша электрон документ рәвешендә электрон формада бирү мөмкинлеге бар. Әлеге Регламентның 2.5 нче пунктында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәре аша күрсәтелгән документларны тапшыру тәртибе турында консультацияләр үткәрү мөмкинлеге бар.<br>Электрон формада дәүләт хезмәте күрсәткәндә | |

| | | |
|---|---|---|
| | гариза бирүче түбәндәгеләргә хокуклы:<br>а) Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр (функцияләр) бердәм порталында, Татарстан Республикасы Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталында урнаштырылган дәүләт хезмәте күрсәтү тәртибе һәм вакытлары турында мәгълүмат алырга;<br>б) Татарстан Республикасы Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталыннан файдаланып, дәүләт хезмәте күрсәтү турында гариза һәм дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле башка документлар, шул исәптән электрон рәвешләре 210-ФЗ номерлы Федераль законның 16 нчы маддәсендәге 1 нче өлешенең 72 нче пункты нигезендә элегрәк расланган документлар һәм мәгълүмат алуга гариза бирергә;<br>в) электрон формада бирелгән дәүләт хезмәте күрсәтү турындагы гаризаларны үтәү барышы турында мәгълүмат алырга;<br>г) дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен электрон документ рәвешендә алырга;<br>д) Министрлык карарына һәм гамәленә (гамьсезлегенә), шулай ук аның вазыйфаи затларына, дәүләт хезмәткәрләренә Татарстан Республикасы Дәүләт һәм муниципаль | |

| | | |
|---|---|---|
| | хезмәтләр порталы, дәүләт һәм муниципаль хезмәт күрсәтә торган органнар, аларның вазыйфаи затлары, дәүләт һәм муниципаль хезмәткәрләр тарафыннан дәүләт һәм муниципаль хезмәт күрсәткән чакта башкарылган карарлар һәм гамәлләргә (гамьсезлеккә) судка кадәр (судтан тыш) шикаять бирү процессын тәэмин итү торган федераль дәүләт мәгълүмати системасы порталы ярдәмендә шикаять бирергә.<br>Гаризаны формалаштыру Татарстан Республикасы Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталында электрон гариза тутыру рәвешендә тормышка ашырыла. Башка төр өстәмә гариза бирү ихтыяҗы юк.<br>Дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе Татарстан Республикасы Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталы аша электрон документ рәвешендә, әгәр Татарстан Республикасы Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталы аша җибәрелгән гаризада күрсәтелгән булса, электрон имза белән бирелә.<br>Электрон рәвештә гариза әзерләгән чакта гариза бирүче түбәндәге мөмкинлекләр белән тәэмин ителә:<br>гариза һәм хезмәт күрсәтү өчен кирәкле башка | |

| | | |
|---|---|---|
| | документларның күчермәсен алу һәм саклау;<br>электрон форма гаризаның кәгазьдәге күчермәсен бастырып алу;<br>кулланучының теләге буенча электрон формага элегрәк кертелгән, шул исәптән электрон формага мәгълүмат керткәндә һәм мәгълүматны яңадан кертү өчен кире кайтарган мәгълүматны саклап калу;<br>ИАБСда урнаштырылган мәгълүматлардан һәм Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталында урнаштырылган мәгълүматлардан файдаланып, ИАБСда булмаган мәгълүматларга кагылышлы өлешендә гариза бирүче мәгълүматны кертә башлаганчы ук электрон формадагы кырларны тутыру;<br>элек кертелгән мәгълүматны югалтмыйча электрон форманы тутыруның теләсә кайсы этабына кайту мөмкинлеге;<br>мөрәҗәгать итүченең Татарстан Республикасы Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталында элек бирелгән мөрәҗәгатьләренә керү мөмкинлеге.<br>Гариза бирүченең шәхесе хисап язмасын активлаштырганда расланган булса, гариза җибәргәндә гади электрон имза кулланыла.<br>Гаризалар кабул итүгә язылу (алга таба – язылу) | |

| | | |
|---|---|---|
| | Татарстан Республикасы Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталы аша кабул ителә.<br>Татарстан Республикасы Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталы аша алдан язылуны гамәлгә ашыру өчен гариза бирүчегә система аша соралган мәгълүматларны күрсәтергә кирәк, шул исәптән:<br>фамилия, исем, атасының исеме (соңгысы – булган очракта);<br>телефон номеры;<br>электрон почта адресы (теләк буенча);<br>кабул итүне теләгән көн һәм вакыт.<br>Гариза бирүче алдан язылган чакта күрсәткән мәгълүматлар шәхси кабул итү вакытында гариза бирүче тәкъдим иткән документлар белән туры килмәгән очракта, алдан язылу гамәлдән чыгарыла.<br>Алдан язылуны гамәлгә ашырганда гариза бирүчегә талон-раслауны бастыру мөмкинлеге бирелә. Мөрәҗәгать итүче электрон почта адресын хәбәр иткән очракта, күрсәтелгән адреска шулай ук кабул итү датасы, вакыты һәм урыны күрсәтелгән алдан языluны раслау турында мәгълүмат җибәрелә.<br>Алдан язылуны гамәлгә ашырганда гариза бирүчегә мәҗбүри тәртиптә билгеләнгән кабул | |

| | | |
|---|---|---|
| | итү вакытыннан 15 минут узгач та килмәгән очракта алдан язылуның гамәлдән чыгарылуы турында хәбәр ителә.<br>Гариза бирүче теләсә кайсы вакытта алдан язылудан баш тартырга хокуклы.<br>Мөрәҗәгать итүчедән, Россия Федерациясенең норматив хокукый актлары нигезендә идентификация һәм аутентификация узудан, кабул итү максатын күрсәтүдән, шулай ук кабул итү өчен кирәк булачак вакыт дәвамлылыгын исәпләү өчен мөһим мәгълүматлардан башка гамәлләр кылуны таләп итү тыела. | |

## 3.Административ процедураларның (гамәлләрнең) составы, эзлеклелеге һәм үтәү вакыты, аларны үтәү тәртибенә карата таләпләр, шул исәптән электрон формадагы административ процедураларны (гамәлләрне) үтәү үзенчәлекләре

3.1. Дәүләт хезмәтен күрсәткән вакытта гамәлләр эзлеклелеген сурәтләү.

3.1.1. Дәүләт хезмәтен күрсәтү түбәндәге процедураларны үз эченә ала:

1) гариза бирүчегә ярдәм күрсәтү, шул исәптән дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен кирәк булган гаризаны рәсмиләштерү өлешендә дә ярдәм күрсәтүне күз алдында тота торган консультация бирү;

2) гариза һәм документларны кабул итү һәм теркәү;

3) спорт разрядын, «Беренче категория спорт хөкемдары» спорт хөкемдары квалификация категориясен бирү, мәхрүм итү, яңадан торгызу турында боерык проектын әзерләү;

4) спорт исемен, «Бөтенроссия категорияле спорт хөкемдары» квалификация категориясен бирү, мәхрүм итү һәм яңадан торгызу өчен Россия Федерациясе Спорт министрлыгына тәкъдим итү хатын әзерләү һәм җибәрү;

5) бирелгән разряд турындагы тамга белән спортчының зачет квалификация кенәгәсен (биргәндә билгеләнгән разряд билгесе белән) бирү;

6) бирелгән хөкемдарлык категориясе тамгасы белән «Беренче категорияле спорт хөкемдары» зачет квалификация кенәгәсен (биргәндә билгеләнгән категория значогы белән) бирү;

7) техник хатаны (язудагы хата, басмадагы хата, грамматик хаталар) төзәтү.

3.2. Гариза бирүчегә консультация бирү, гариза бирүчегә, шул исәптән дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен кирәк булган документларның билгеләнгән комплектын рәсмиләштерү өлешендә ярдәм күрсәтү.

Гариза бирүче Бүлеккә шәхсән, телефон аша һәм (яисә) почта аша (шул исәптән электрон почта аша) дәүләт хезмәтләрен алу тәртибе турында консультация алу өчен мөрәҗәгать итәргә хокуклы.

Бүлек белгече гариза бирүчегә, шул исәптән гариза формасы һәм дәүләт хезмәте күрсәтүен алу өчен башка мәсьәләләр буенча да консультация үткәрә . Кирәк булганда, Бүлек белгече гариза бирүчегә шул исәптән дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәк булган гаризаны рәсмиләштерү өлешендә дә ярдәм күрсәтә.

Әлеге пункт белән билгеләнелә торган процедура Гариза бирүче мөрәҗәгать иткән көнне тормышка ашырыла.

Процедура нәтиҗәсе: консультация бирү, гариза бирүчегә шул исәптән дәүләт

хезмәте күрсәтү өчен кирәк булган гариза һәм документларның билгеләнгән комплектын рәсмиләштерү өлешендә ярдәм күрсәтү.

3.3. Гариза һәм документларны кабул итү һәм теркәү

3.3.1. Гариза бирүче дәүләт хезмәте күрсәтү турында гариза белән шәхсән үзе, почта, «Интернет» челтәре, электрон почта аша мөрәҗәгать итә.

Гариза Татарстан Республикасы Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталы аша бирелергә мөмкин.

3.3.2. Министрлыкка гариза бирелгәндә Бүлек белгече:

- гаризада билгеләнгән форма буенча мәгълүматның (белешмәләр, мәгълүмат), билгеләнгән документларның комплектлылыгы буенча булуын;

- гаризада бирелгән мәгълүматларның документлар комплектындагы белешмәләргә туры килүен тикшерә.

Гариза һәм әлеге административ регламентның 2.7 пунктында каралган документларны кабул итүдән баш тарту өчен нигез булмаган очракта Бүлек белгече:

документларны кабул итә һәм терки;

гариза бирүчегә почта аша яисә электрон почта аша (аның теләге буенча) гаризаның, кергәндә бирелгән номеры, документларны кабул итү датасы турындагы тамгалар белән күчермәләрен тапшыра яисә җибәрә;

Татарстан Республикасы спорт министрына (алга таба – министр) Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнарының электрон документ әйләнешенең бердәм ведомствоара системасы – «Электрон Хөкүмәт» (алга таба – электрон документ әйләнеше) аша гаризаны җибәрә.

Гаризалар һәм документларны кабул итүдән баш тарту өчен нигез булган очракта Бүлек белгече, әлеге Регламентның 2.7 пунктында күрсәтелгән документларны кабул итүдән баш тарту сәбәпләрен нигезләп, язмача баш тарту әзерли.

Гаризаны Татарстан Республикасы Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталы аша биргән очракта гаризаны теркәүдән баш тарту турында хәбәр баш тарту сәбәпләрен аңлатып гариза бирүченең Татарстан Республикасы Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталындагы шәхси кабинетына юллана.

Әлеге пункт белән билгеләгән процедура гариза кергән көнне гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: кабул ителгән, теркәлгән һәм министрга җибәрелгән гариза яки Гариза бирүчегә гариза кабул итүдән баш тарту турында язмача хәбәр.

3.3.3. Министр гаризаны карый һәм карау өчен министрның беренче урынбасарына җибәрә.

Әлеге пункт белән билгеләнә торган процедура гариза теркәлгән көнне гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: карау өчен министрның беренче урынбасарына җибәрелгән гариза.

3.3.4. Министрның беренче урынбасары гаризаны карый һәм карау өчен Бүлек башлыгына җибәрә.

Әлеге пункт белән билгеләнә торган процедура гариза теркәлгән көнне гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: карау өчен Бүлек башлыгына җибәрелгән гариза

3.3.5. Бүлек җитәкчесе гаризаны үтәү өчен Бүлекнең җаваплы белгеченә җибәрә.

Әлеге пункт белән билгеләнә торган процедура гариза теркәлгән көнне гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: үтәү өчен Бүлек белгеченә җибәрелгән гариза.

3.4. Дәүләт хезмәтен күрсәтүдә катнаша торган органнарга ведомствоара мөрәҗәгатьләр формалаштыру һәм юллау

3.4.1. Бүлек белгече электрон формада ведомствоара электрон хезмәттәшлек системасы аша 14 яше тулмаган балигъ булмаган бала туу турында мәгълүмат бирү турында мөрәҗәгать җибәрә.

Әлеге пункт белән билгеләнә торган процедуралар гариза кергән көнне башкарыла.

Процедура нәтиҗәсе: мәгълүмат бирү турында мөрәҗәгать.

3.4.2. Ведомствоара хезмәттәшлек органы белгечләре ведомствоара электрон хезмәттәшлек системасы аша кергән мөрәҗәгатьләр нигезендә соратып алына торган документларны (белешмәләрне) тапшыра.

Әлеге пункт белән билгеләнә торган процедуралар закон тарафыннан билгеләнгән вакытта башкарыла.

Процедура нәтиҗәсе: Бүлеккә юлланган мәгълүмат яисә баш тарту турында хәбәр.

3.5. Гаризаны карау һәм аның буенча карар кабул итү.

3.5.1. Бүлек Белгече:

спорт разрядын, «спорт мастерлыгына кандидат» һәм «беренче спорт разряды», спорт хөкемдарының «беренче категорияле спорт хөкемдары» квалификация категориясен бирү, мәхрүм итү, яңадан торгызу өчен нигезләр булу – булмавына документларны карый һәм бирү турында боерык проектын яисә гариза бирүчегә, баш тарту сәбәпләрен күрсәтеп, хат (алга таба – боерык проекты, хат) әзерли.

Россия Федерациясе Спорт министрлыгына тапшыруга бергә теркәлгән хат проектын яки, баш тарту сәбәпләрен күрсәтеп, Гариза бирүчегә спорт исеме бирү һәм

«бөтенроссия категориясендәге спорт хөкемдары» квалификация категориясен бирү, мәхрүм итү өчен тәкъдим юллаудан баш тарту турындагы хат проектын әзерли (алга таба – бергә теркәлгән хат проекты).

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедуралар үтәү өчен Бүлек белгеченә гариза җибәрелгәннән соң бер эш көне эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: боерык проектлары, хатлар, бергә теркәлгән хат проекты Бүлек башлыгына килештерүгә җибәрелә.

3.5.2. Бүлек башлыгы әзерләнгән боерык проектларының, хат, бергә теркәлгән хатның дөреслеген тикшерә, аларны килештерә һәм килештерүгә министрның беренче урынбасарына җибәрә.

Әлеге пункт белән билгеләнә торган процедура Бүлек башлыгына һәм министрның беренче урынбасарына килештерүгә кергән көнне гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: Бүлек башлыгына һәм министрның беренче урынбасарына килештерүгә юлланган боерык, хат проектлары, бергә теркәлгән хат проекты.

3.5.3. Министрның беренче урынбасары боерык, баш тарту турындагы хат проектларына, бергә теркәлгән хат проектына рөхсәт имзасын куя, бүлеккә җибәрә.

Әлеге пункт белән билгеләнә торган процедура боерык, баш тарту турындагы хат проектларының, бергә теркәлгән хат проектының министрның беренче урынбасарына килештерүгә кергән вакыттан соң бер эш көне эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: министрның беренче урынбасары визасы белән боерык, хат проектлары, бергә теркәлгән хат проекты.

3.5.4. Бүлек белгече килештерелгән боерык, баш тарту турындагы хат проектларын, бергә теркәлгән хат проектын кул кую өчен министрга җибәрә.

Әлеге пункт белән билгеләнә торган процедура боерык, баш тарту турындагы хат проектларын, бергә теркәлгән хат проектын министрның беренче урынбасары белән килештерелгән көнне гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: министрга кул куярга юлланган боерык, хат проектлары, бергә теркәлгән хат проекты.

3.5.5. Министр Россия Федерациясе Спорт министрлыгына җибәрелә торган боерык проектларын, хат проектын, бергә теркәлгән хат проектын имзалый.

Әлеге пункт белән билгеләнә торган процедура боерык, баш тарту турындагы хат проектларын, бергә теркәлгән хат проектын министрга кул куюга җибәргәннән соң бер эш көне эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: боерык, баш тарту турында хат, министр имзалаган бергә теркәлгән хат.

3.5.6. Оештыру эше, эш башкару һәм тикшерү бүлеге белгече боерыкны, бергә теркәлгән хатны, Гариза бирүчегә җибәрелә торган бирүдән баш тарту турындагы хатны терки.

Әлеге пункт белән билгеләнә торган процедура имзалау өчен документлар кергән көнне гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: Министрлык боерыгы, бергә теркәлгән хат, разряд яисә хөкемдарлык категориясен бирүдән баш тарту турында Гариза бирүчегә җибәрелгән хат.

3.5.7. Бүлек белгече Министрлык боерыгын Министрлыкның рәсми сайтында урнаштыра.

Әлеге пункт белән билгеләнә торган процедура боерыкны теркәү көнендә гамәлгә ашырыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: Министрлыкның рәсми сайтында урнаштырылган Министрлык боерыгы.

3.6. Бүлек белгече:

3.6.1 зачет квалификация кенәгәсендә спорт разряды яки спорт хөкемдары кенәгәсендә спорт хөкемдарының квалификация категориясен бирү турында билге ясый:

гариза бирүче беренче тапкыр мөрәҗәгать иткән очракта, бирелгән разряд белән зачет квалификация кенәгәсен яисә бирелгән категория белән спорт хөкемдары кенәгәсен бирә.

Әлеге пункт тарафыннан билгеләнә торган процедура алдагы процедураны үткәрү көне дәвамында гамәлгә ашырыла.

Нәтиҗә: гариза бирүчегә зачет кенәгәсен бирү.

3.6.2. Россия Федерациясе Спорт министрлыгына тәкъдим итүгә бергә теркәлгән хат һәм билгеләнгән документлар комплектын яки, баш тарту сәбәбен күрсәтеп, гариза бирүчегә спорт исеме бирү һәм «бөтенроссия категорияле спорт хөкемдары» квалификация категориясен бирү, мәхрүм итү өчен тәкъдим бирүдән баш тарту турындагы хат проектын җибәрә.

Мөрәҗәгать итүче Татарстан Республикасы Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталы аша мөрәҗәгать иткән очракта, мөрәҗәгать итүченең шәхси кабинетына, сәбәпләрен күрсәтеп, дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту турында автомат рәвештә хәбәр җибәрелә.

Әлеге пункт тарафыннан билгеләнә торган процедура алдагы процедураны үткәрү көне дәвамында гамәлгә ашырыла.

Нәтиҗә: гариза бирүчегә баш тарту турында хат.

3.7. Техник хаталарны (язудагы хата, басмадагы хата, грамматик яки арифметик хаталар) (алга таба – техник хата) төзәтү.

Спорт разряды бирү турында зачет квалификация кенәгәсен һәм спорт хөкемдары квалификация категориясен бирү турында спорт хөкемдары кенәгәсен яңадан рәсмиләштерү аларда техник хаталарны (язудагы хата, басмадагы хата, грамматик хаталар) (алга таба – техник хата) юкка чыгаруга бәйле рәвештә гамәлгә ашырыла.

Техник хатаны төзәтү турында гариза Гариза бирүче тарафыннан шәхсән тапшырыла яисә почта аша җибәрелә.

Спорт разряды бирү турында зачет квалификация кенәгәсен һәм спорт хөкемдары квалификация категориясен бирү турында спорт хөкемдары кенәгәсен яңадан рәсмиләштерү теркәлгән гариза (тәкъдим ителә торган форма әлеге Регламентның 9 нчы кушымтасында китерелгән) нигезендә гамәлгә ашырыла, аңа техник хата булган спорт разряды бирү турында зачет квалификация кенәгәсе яки спорт хөкемдары квалификация категориясен бирү турында спорт хөкемдары кенәгәсе теркәлә.

3.7.1 Оештыру эшләре, эш башкару һәм тикшерү бүлеге (алга таба – Оештыру бүлеге) белгече:

теркәлгән документлар белән техник хаталарны төзәтү турында гаризаны кабул итә һәм терки;

бердәм ведомствоара электрон документ әйләнеше системасы аша электрон формада техник хаталарны төзәтү турында гаризаны министрга җибәрә.

Әлеге пункт белән билгеләнә торган процедура техник хатаны төзәтү турында гариза кергән көнне гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: техник хатаны төзәтү турында кабул ителгән, теркәлгән һәм министрга җибәрелгән гариза.

3.7.2. Министр техник хаталарны төзәтү турындагы гаризаны карый һәм карау өчен министрның беренче урынбасарына җибәрә.

Әлеге пункт тарафыннан билгеләнә торган процедура техник хатаны төзәтү турында гаризаны теркәү көнендә гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: министрның беренче урынбасарына карап тикшерүгә җибәрелгән техник хаталарны төзәтү турында гариза.

3.7.3. Министрның беренче урынбасары техник хатаны төзәтү турындагы гаризаны карый һәм карау өчен Бүлек башлыгына җибәрә.

Әлеге пункт тарафыннан билгеләнә торган процедура техник хатаны төзәтү турында гаризаны теркәү көнендә гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: Бүлек башлыгына карауга җибәрелгән техник хатаны төзәтү турында гариза.

3.7.4. Бүлек башлыгы Бүлек белгечен билгели һәм аңа башкару өчен техник хатаны төзәтү турында гаризаны тапшыра.

Әлеге пункт белән билгеләнә торган процедура техник хатаны төзәтү турында гаризаны теркәү көнендә гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: Бүлек белгеченә юлланган техник хатаны төзәтү турында гариза.

3.7.5. Бүлек белгече:

спорт разряды бирү турында зачет квалификация кенәгәсен яки спорт хөкемдары квалификация категориясен бирү турында спорт хөкемдары кенәгәсен яңадан рәсмиләштерә;

гариза бирүчегә спорт разряды бирү турында зачет квалификация кенәгәсен яки спорт хөкемдары квалификация категориясен бирү турында спорт хөкемдары кенәгәсен яңадан рәсмиләштерү турында хат проектын әзерли һәм килештерү өчен Бүлек башлыгына җибәрә.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедуралар башкару өчен Бүлек белгеченә техник хатаны төзәтү турында гаризаны җибәргәннән соң бер эш көне эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: Бүлек башлыгына килештерүгә җибәрелгән спорт разрядын бирү турында зачет квалификация кенәгәсе яки спорт хөкемдарының спорт хөкемдары квалификация категориясен бирү турындагы кенәгәсе, мөрәҗәгать итүчегә хат проекты.

3.7.6. Бүлек башлыгы әзерләнгән спорт разряды бирү турында зачет квалификация кенәгәсен яки спорт хөкемдары квалификация категориясен бирү турында спорт хөкемдары кенәгәсенең дөреслеген тикшерә, гариза бирүчегә хат проектын килештерә һәм аны министрның беренче урынбасарына килештерүгә җибәрә.

Әлеге пункт белән билгеләнә торган процедура спорт разряды бирү турында зачет квалификация кенәгәсен һәм спорт хөкемдары квалификация категориясен бирү турында спорт хөкемдары кенәгәсе һәм хат проекты Бүлек башлыгына килештерүгә кергән көнне гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: министрның беренче урынбасарына килештерүгә юлланган хат проекты.

3.7.7. Министрның беренче урынбасары гариза бирүчегә аңа теркәп бирелә торган спорт разряды бирү турында зачет квалификация кенәгәсе яки спорт хөкемдары

квалификация категориясен бирү турында спорт хөкемдары кенәгәсе белән хат проектын килештерә һәм Бүлеккә җибәрә.

Әлеге пункт белән билгеләнә торган процедура Бүлек башлыгыннан хат проекты кергән көнне гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: спорт разряды бирү турында зачет квалификация кенәгәсе яки спорт хөкемдары квалификация категориясен бирү турында спорт хөкемдары кенәгәсе белән килештерелгән хат проекты.

3.7.8. Бүлек белгече килештерелгән хат проектын кул кую өчен министрга җибәрә.

Әлеге пункт белән билгеләнә торган процедура хат проектының министрның беренче урынбасары тарафыннан килешенгән көнендә гамәлгә ашырыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: министрга кул кую өчен юлланган хат проекты.

3.7.9. Министр гариза бирүчегә дәүләт хезмәте күрсәтү турында хат проектын имзалый.

Әлеге пункт белән билгеләнә торган процедура министрга имза салу өчен хат проекты җибәргән көннән соң бер эш көне эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: министр имзалаган гариза бирүчегә хат.

3.7.10. Бүлек белгече министр имзалаган хат белән бергә спорт разряды бирү турында зачет квалификация кенәгәсен яки спорт хөкемдары квалификация категориясен бирү турында спорт хөкемдары кенәгәсен Оештыру бүлегенә җибәрә.

Әлеге пункт белән билгеләнә торган процедура гариза бирүчегә хатны министр имзалаган көнне гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: Оештыру бүлегенә юлланган гариза бирүчегә хат.

3.7.11. Оештыру бүлеге белгече министр тарафыннан имзаланган дәүләт хезмәте күрсәтү турында хатны теркәүне гамәлгә ашыра һәм гариза бирүче күрсәткән почта адресына юллый яки гаризада күрсәтелгән очракта үз кулына тапшыра.

Әлеге пункт белән билгеләнә торган процедура гариза бирүчегә хатны министр имзалаган көнне гамәлгә ашырыла.

Процедура нәтиҗәсе: гариза бирүчегә юлланган хат.

3.7.12. Бүлек белгече спорт разряды бирү турында зачет квалификация кенәгәсен яки спорт хөкемдары квалификация категориясен бирү турында спорт хөкемдары кенәгәсе кулына бирә.

Әлеге пункт белән билгеләнә торган процедура гариза бирүче килгән көнне гамәлгә ашырыла.

Нәтиҗә: техник хата төзәтелгән спорт разряды бирү турында зачет квалификация кенәгәсе яки спорт хөкемдары квалификация категориясен бирү турында спорт хөкемдары кенәгәсен бирү.

## 4. Дәүләт хезмәте күрсәтүне тикшерү тәртибе һәм формалары

4.1. Дәүләт хезмәтен күрсәтүнең тулылыгын һәм сыйфатын тикшерү Гариза бирүчеләрнең хокукларын бозуларны ачыклау һәм юкка чыгаруны, шикаятьләр карау, тикшерүләр уздыру, карарлар кабул итү һәм гариза бирүчеләр мөрәҗәгатьләренә җавап әзерләүне, Министрлыкның вазыйфаи затларының гамәлләренә (гамьсезлекләренә) карарлар әзерләүне үз эченә ала.

Административ процедураларны үтәлешен саклауны тикшерү формалары булып:

- хезмәт күрсәтү буенча документлар проектларына экспертиза уздыру. Экспертиза нәтиҗәсе булып проектларны визалау тора;
- билгеләнгән тәртиптә контроль тикшерүләр уздыру;
- билгеләнгән тәртиптә уздырыла торган Бүлектә эш алып баруны тикшерүләр тора.

Тикшерүләр планлы (Министрлыкның яртыеллык яки еллык эш планнары нигезендә уздырылырга) һәм планнан тыш булырга мөмкин. Планлы тикшерүләр уздыру вакытында хезмәт күрсәтү белән бәйле барлык мәсьәләләр (комплекслы тикшерүләр) яки гариза бирүченең конкрет мөрәҗәгате буенча мәсьәләләр каралырга мөмкин.

4.2. Хезмәт күрсәтү буенча административ процедуралар билгеләгән гамәлләрнең эзлеклелеген саклауны агымдагы тикшерү министр урынбасары тарафыннан башкарыла.

Дәүләт хезмәте күрсәткәндә һәм карарлар кабул иткәндә гамәлләрне башкаруны контрольдә тотуны гамәлгә ашыру өчен министр урынбасарына муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәләре турында белешмәләр бирелә.

Белгечләр административ процедураларның вакытларын, эзлеклелеген һәм эчтәлеген бозу очраклары һәм сәбәпләре турында дәүләт хезмәте күрсәтүче орган җитәкчесенә кичекмәстән хәбәр итәләр, шулай ук бозуларны бетерү буенча ашыгыч чаралар күрәләр.

4.3. Агымдагы тикшерүне гамәлгә ашыручы вазыйфаи затлар исемлеге министрлыкның структур бүлекчәләре турында нигезләмәләр, вазыйфаи регламентлар белән билгеләнә.

Үткәрелгән тикшерүләр нәтиҗәләре буенча гариза бирүчеләрнең хокукларын бозулар ачыкланган очракта гаепле затлар Россия Федерациясе законнары буенча җаваплылыкка тартыла.

4.4. Югары казанышлар спортын үстерү бүлеге башлыгы мөрәҗәгать итүчеләрнең сорауларын вакытында карауны тикшереп тора.

Дәүләт хезмәте күрсәтү барышында кабул ителә (гамәлгә ашырыла) торган карарлар һәм гамәлләр (гамьсезлекләр) өчен җаваплы башкаручылар законда билгеләнгән тәртиптә җаваплы булалар.

4.5. Гражданнар, аларның берләшмәләре һәм оешмалары ягыннан дәүләт хезмәте күрсәтүне тикшерү дәүләт хезмәте күрсәткәндә Министрлык эшчәнлегенең ачык булуы, дәүләт хезмәте күрсәтү тәртибе һәм дәүләт хезмәте күрсәтү процессында мөрәҗәгатьләр (шикаятьләр) карауның судка кадәр карау мөмкинлеге турында тулы, актуаль һәм дөрес мәгълүмат бирү юлы белән тормышка ашырыла.

## 5. Дәүләт хезмәте күрсәтә торган органның, дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең күпфункцияле үзәге, 2010 елның 27 июленнән 210-ФЗ номерлы Федераль законның 16 маддәсе $1^1$ өлешендә күрсәтелгән оешмалар, шулай ук аларның вазыйфаи затлары, дәүләт хезмәткәрләренең, эшчеләренең карарларына һәм гамәлләренә (гамьсезлегенә) судка кадәр (судтан тыш) дәгъва бирү тәртибе

5.1. Гариза бирүчеләр Министрлык, Министрлыкның вазыйфаи заты яисә Министрлыкның дәүләт гражданлык хезмәткәренең гамәлләренә (гамьсезлегенә) карата судка кадәр – Министрлыкка дәгъва бирергә хокуклы. Министр кабул иткән дәүләт хезмәте күрсәтү белән бәйле карарларга, гамәлләргә (гамьсезлеккә) шикаятьләр Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына бирелә.

Гариза бирүче шикаять белән, шул исәптән түбәндәге очракларда мөрәҗәгать итә ала:

1) дәүләт хезмәте күрсәтү турында сорауны (запрос) теркәү вакытын бозу;

2) дәүләт хезмәте күрсәтүнең вакытын бозу;

3) гариза бирүчедән дәүләт хезмәте күрсәтү өчен Россия Федерациясе, Татарстан Республикасы норматив хокукый актларында каралмаган документлар яисә мәгълүматларны яки гамәлләрне тормышка ашыруны таләп итү;

4) гариза бирүчедән дәүләт хезмәте күрсәтү өчен Россия Федерациясе, Татарстан Республикасы норматив хокукый актларында каралган документларны кабул итүне кире кагу;

5) әгәр кире кагу өчен сәбәпләр федераль законнар, аларга бәйле рәвештә кабул ителгән башка Россия Федерациясе норматив хокукый актлары, Татарстан Республикасы законнары һәм башка норматив хокукый актлары белән каралмаган булса, дәүләт хезмәте күрсәтүне кире кагу;

6) дәүләт хезмәте күрсәткәндә гариза бирүчедән Россия Федерациясе, Татарстан Республикасы норматив хокукый актларында каралмаган түләү кертүне таләп итү;

7) дәүләт хезмәте күрсәтә торган Министрлык, аның дәүләт хезмәте күрсәтә торган вазыйфаи заты дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсендә бирелгән документларда җибәрелгән хаталар яисә хәреф хаталарын төзәтүдән баш тарткан яисә шундый төзәтүләрнең билгеләнгән вакытын бозу;

8) дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәләре буенча документлар бирү вакытын яисә тәртибен бозу;

9) федераль законнар һәм алар нигезендә кабул ителгән Россия Федерациясенең

башка норматив хокукый актлары, Татарстан Республикасы законнары һәм башка норматив хокукый актлары белән каралмаган очракта дәүләт хезмәте күрсәтүне туктату;

10) гариза бирүчедән дәүләт хезмәте күрсәткәндә кирәк булган документларны кабул итүдән беренчел баш тартканда дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен кирәк булган документлар яки мәгълүматның булмавы һәм (яки) дөрес түгеллеге күрсәтелмәгәндә яисә 210-ФЗ федераль законының 7 маддәсе 1 өлеше 4 пункты белән каралган очраклардан тыш дәүләт хезмәтен күрсәтүдән баш тартканда аларны таләп итү.

5.2. Шикаять язма формада кәгазьдә яки электрон формада бирелә.

Шикаять почта, дәүләт һәм муниципаль хезмәт күрсәтүләрнең күпфункцияле үзәге аша, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәреннән, Министрлыкның рәсми сайтыннан http://minsport.tatarstan.ru файдаланып, Татарстан Республикасы Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләре порталы (http://uslugi.tatarstan.ru/), Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләренең (функцияләре) бердәм порталы (https://www.gosuslugi.ru) аша җибәрелергә, шулай ук гариза бирүчедән шәхси кабул итү вакытында алынырга мөмкин.

5.3. Шикаятьне карау срогы – аны теркәгән көннән соң 15 эш көне эчендә. Дәүләт хезмәте күрсәтүче орган, дәүләт хезмәте күрсәтүче органның вазыйфаи затының мөрәҗәгать итүчедән документлар кабул итүдән яисә җибәрелгән хәреф хаталарын һәм хаталарны төзәтүдән баш тартуына дәгъва белдерелгән очракта яисә шундый төзәтүләрнең билгеләнгән вакыты бозылуга шикаять бирелгән очракта – аны теркәгән көннән биш эш көне эчендә.

5.4. Шикаятьтә түбәндәге мәгълүмат булырга тиеш:

1) карарлары яисә гамәлләренә (гамьсезлегенә) шикаять бирелә торган дәүләт хезмәте күрсәтә торган орган атамасы, дәүләт хезмәте күрсәтә торган органның вазыйфаи заты яки дәүләт гражданлык хезмәткәренең исеме.

2) гариза бирүче – физик затның фамилиясе, исеме, атасының исеме (соңгысы – булган очракта), тору урыны турында мәгълүмат яисә гариза бирүче – юридик затның атамасы, урнашкан урыны, шулай ук элемтә өчен телефон номеры (номерлары), гариза бирүчегә җавап җибәрелергә тиеш булган электрон почта (булган очракта) адресы (адреслары) һәм почта адресы;

3) дәүләт хезмәте күрсәтә торган орган, дәүләт хезмәте күрсәтә торган органның вазыйфаи заты яисә дәүләт гражданлык хезмәткәренең дәгъвалана торган карарлары һәм гамәлләре (гамьсезлеге) турында мәгълүмат;

4) гариза бирүченең дәүләт хезмәте күрсәтә торган орган, дәүләт хезмәте күрсәтә торган органның вазыйфаи заты яисә дәүләт гражданлык хезмәткәренең карары һәм

гамәле (гамьсезлеге) белән килешмәү өчен нигез булып торган дәлилләре. Гариза бирүче тарафыннан аның дәлилләрен раслый торган документлар (булган очракта) яисә аларның күчерелмәләре тәкъдим ителергә мөмкин.

5.5. Шикаятьне карау нәтиҗәләре буенча түбәндәге карарларның берсе кабул ителә:

1) шикаять канәгатьләндерелә, шул исәптән кабул ителгән карарны юкка чыгару, дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсендә бирелгән документларда җибәрелгән хаталар һәм хәреф хаталарын төзәтү, гариза бирүчегә аларны алу Россия Федерациясе норматив хокукый актлары, Россия Федерациясе субъектлары норматив хокукый актларында каралмаган акчаларны кире кайтару формасында;

2) шикаятьне канәгатьләндерүдән баш тартыла.

Әлеге пунктта күрсәтелгән карар кабул ителгән көннән соңгы көннән дә соңга калмыйча гариза бирүчегә язма рәвештә һәм гариза бирүче теләге буенча электрон формада шикаятьне карау нәтиҗәләре турында дәлилләнгән җавап җибәрелә.

5.6. Шикаятьне канәгатьләндерерлек дип тапкан очракта, гариза бирүчегә әзерләнгән җавапта дәүләт хезмәтен күрсәткәндә җибәрелгән бозуларны кичекмәстән юкка чыгару максатында Министрлык тарафыннан тормышка ашырыла торган гамәлләр турында мәгълүмат бирелә, шулай ук җибәрелгән уңайсызлыклар өчен гафу үтенелә һәм гариза бирүчегә алга таба дәүләт хезмәтен алу максатларында кирәк булган гамәлләр турында мәгълүмат күрсәтелә.

5.7. Шикаятьне канәгатьләндерерлек түгел дип тапкан очракта, гариза бирүчегә җавапта әлеге кабул ителгән карар сәбәпләре турында дәлилләнгән аңлатма, шулай ук кабул ителгән карар буенча шикаять язу тәртибе турында мәгълүмат бирелә.

5.8. Шикаятьне карау барышында яисә аның нәтиҗәләре буенча административ хокук бозу составы яисә җинаять билгеләре ачыкланган очракта шикаятьләр карау буенча вәкаләтләре булган вазыйфаи зат булган материалларны кичекмәстән прокуратура органнарына юллый.

«Спорт мастерлыгына кандидат» һәм «беренче спорт разряды» спорт разрядларын, «беренче категорияле спорт хөкемдары» квалификация категориясен бирү, аннан мәхрүм итү, яңадан торгызу буенча һәм Россия Федерациясе Спорт министрлыгына спорт исемнәрен, «бөтенроссия категорияле спорт хөкемдары» квалификация категориясен бирү, мәхрүм итү һәм яңадан торгызу өчен тәкъдимнәр юллау буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына 1 нче кушымта
(тәкъдим ителә торган форма)

Татарстан Республикасы Спорт министрлыгы

**Россия Федерациясе Спорт министрлыгына спортчы**

______________________________________________________________________________
(Ф.И.А.и.)
_____________________________
**бирергә тәкъдим юллау турында гариза**

Кушымта:

________________________________________________________
(ББСК буенча билгеләнгән документлар комплекты)
.

_________________________________________________________________
Үтенеч язуын юллый торган оешмадан вәкаләтле вәкилнең вазыйфа атамасы, имзасы, фамилия һәм инициаллары

--------------------------------
<*> Оешма (региональ спорт оешмасы) бланкы белән рәсмиләштерелә

Гаризаны теркәү турында билге «___» ____________ ел №

«Спорт мастерлыгына кандидат» һәм «беренче спорт разряды» спорт разрядларын, «беренче категорияле спорт хөкемдары» квалификация категориясен бирү, аннан мәхрүм итү, яңадан торгызу буенча һәм Россия Федерациясе Спорт министрлыгына спорт исемнәрен, «бөтенроссия категорияле спорт хөкемдары» квалификация категориясен бирү, мәхрүм итү һәм яңадан торгызу өчен тәкъдимнәр юллау буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына 2 нче кушымта
(тәкъдим ителә торган форма)

Татарстан Республикасы Спорт министрлыгы

**«Бөтенроссия категорияле спорт хөкемдары»**
**квалификация категориясен бирү турында**
**Россия Федерациясе Спорт министрлыгына үтенеч юллау турында гариза**

Россия Федерациясе Спорт министрлыгына үтенеч юллау мөмкинлеген карауны сорыйбыз

______________________________________________
(Ф.И.А.и.)

Кушымта:

____________________

(Хөкемдарлар турында Нигезләмә буенча билгеләнгән документлар комплекты)

__________________________________________________________________
Үтенеч җибәрә торган оешманың вәкаләтле вәкиленең вазыйфа атамасы, имзасы, фамилия һәм инициаллары

--------------------------------
<*> Үтенеч җибәрә торган оешма (региональ спорт оешмасы) бланкында теркәлә.

Гаризаны теркәү турында белешмә № ____________________
дата

«Спорт мастерлыгына кандидат» һәм «беренче спорт разряды» спорт разрядларын, «беренче категорияле спорт хөкемдары» квалификация категориясен бирү, аннан мәхрүм итү, яңадан торгызу буенча һәм Россия Федерациясе Спорт министрлыгына спорт исемнәрен, «бөтенроссия категорияле спорт хөкемдары» квалификация категориясен бирү, мәхрүм итү һәм яңадан торгызу өчен тәкъдимнәр юллау буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына 3 нче кушымта
(тәкъдим ителә торган форма)

Татарстан Республикасы Спорт министрлыгы

**Спорт разряды бирү турында гариза**

(спорт разряды)

спорт разряды булган

______________________________________________________________________

(Ф.И.А.и.)

спорт разряды "____________________", спорт төре _________________,

_______________________________________________________

Кушымта:

(ББСК нигезе буенча документлар комплектын җыелган)

______________________________________________________________________

Спортчыга тәкъдим итү юллый торган оешманың вәкаләтле затының вазыйфа атамасы, имзасы фамилия һәм инициаллары

<*> Үтенеч җибәрә торган оешма (региональ спорт оешмасы) бланкында теркәлә.

Гаризаны теркәү турында билге № ________________________

дата

«Спорт мастерлыгына кандидат» һәм «беренче спорт разряды» спорт разрядларын, «беренче категорияле спорт хөкемдары» квалификация категориясен бирү, аннан мәхрүм итү, яңадан торгызу буенча һәм Россия Федерациясе Спорт министрлыгына спорт исемнәрен, «бөтенроссия категорияле спорт хөкемдары» квалификация категориясен бирү, мәхрүм итү һәм яңадан торгызу өчен тәкъдимнәр юллау буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына 4 нче кушымта
(тәкъдим ителә торган форма)

Татарстан Республикасы Спорт министрлыгы

**«Беренче категория спорт хөкемдары»**
**квалификация категориясен бирү турында**
**гариза**

______________________________________________
(Ф.И.А.и.)

Кушымта:
________________________________________________________________
(Хөкемдарлар турында Нигезләмә буенча билгеләнгән документлар комплекты)

___________________________________________________________________________
Спортчыга тәкъдим итү юллый торган оешманың вәкаләтле затының вазыйфа атамасы, имзасы фамилия һәм инициаллары
--------------------------------
<*> Үтенеч җибәрә торган оешма (региональ спорт оешмасы) бланкында теркәлә.

Гаризаны теркәү турында билге № ______________________
дата

«Спорт мастерлыгына кандидат» һәм «беренче спорт разряды» спорт разрядларын, «беренче категорияле спорт хөкемдары» квалификация категориясен бирү, аннан мәхрүм итү, яңадан торгызу буенча һәм Россия Федерациясе Спорт министрлыгына спорт исемнәрен, «бөтенроссия категорияле спорт хөкемдары» квалификация категориясен бирү, мәхрүм итү һәм яңадан торгызу өчен тәкъдимнәр юллау буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына 5 нче кушымта
(тәкъдим ителә торган форма)

| **ТӘКЪДИМ ИТҮ** | **СМ (ХКСМ, БХ)**<br>Кирәклесен сайларга<br>**Яшел төстәге бланк**<br>**(сайлаганнан соң, артыгын бетерергә)** | | | | Блокта 2 нөсхә фото<br>(3×4 см) |
|---|---|---|---|---|---|
| Спорт төре | | | | | |
| Фамилиясе | | Исеме | | | |
| Атасының исеме | | Туган көне | көн | ай | ел |
| | | | | | |
| Республика, край, өлкә, округ | | Шәһәр (авыл, бистә) | | | |
| БИФСҖ, ведомство | | Спорт мәктәбе | БЯСМ, БЯОРСМ, ЮСОМ<br>кирәкмәгенне сызарга | | |
| Белеме | | Физик тәрбия буенча белеме | | | |
| Уку (эш) урыны, вазыйфасы | | | | | |
| Өй адресы | | | | | |

| Алдагы исеме | Бирелү яки Раслау вакыты | Спортчыны әзерләгән тренерларның Ф.И.А.и. | Тренер категориясе |
|---|---|---|---|
| | | | |
| | | | |
| | | | |

| Региональ спорт федерациясе | | Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре һәм спорт министрлыгы | |
|---|---|---|---|
| М.У.<br><br>**Җитәкче**<br>(имза) | | М.У.<br><br>Министрның<br>беренче урынбасары<br>Х.Х.Шәйхетдинов ________________<br>(имза) | |
| дата | | дата | |

| ТӨП КҮРСӘТКЕЧЛӘР (нормативлар) | | | Россия Спорт министрлыгына керү көне |
|---|---|---|---|
| | | | |
| Башкару көне | Ярышлар атамасы (дисциплина, авырлык) | Ярышларнык рангы, категориясе | Күрсәтелгән нәтиҗә (хөкемдарның вазыйфасы) |
| көн, ай, | | | |

| | | | |
|---|---|---|---|
| ел | | | |
| | | | |
| | | | |
| | | | |
| | | | |
| | | | |
| | БКП № | | |
| | | | |
| | | | |

| Хөкемдарның вазыйфасы | Фамилияләре, инициаллары | Шәһәр | Хөкемдарлык категориясе |
|---|---|---|---|
| Баш хөкемдар | | | |
| Баш сәркатип | | | |
| Өлкән хөкемдар | | | |
| Документны Федерация, Союз, Ассоциация, Россия Спорт министрлыгы бүлеге тарафыннан раслау | | | |
| Федерация, Союз, Ассоциация карары | Беркетмә номеры | | |
| Федерация (Союз, Ассоциация) Президенты | ____________________(__________________) | | Дата |
| РСМФ җаваплы сәркатибе | ____________________(__________________) | | Дата |
| Җаваплы башкаручы | ____________________(__________________) | | Дата |
| Спорт исемнәрен бирү бүлеге | Имза _________ | | Дата _____________ |
| Хезмәт күрсәтүдән баш тарту сәбәпләрен һәм бозулар турында искәрмәсен күрсәтеп җаваплы затның имзасы | | | Дата _________ Имза _____________ |

«Спорт мастерлыгына кандидат» һәм «беренче спорт разряды» спорт разрядларын, «беренче категорияле спорт хөкемдары» квалификация категориясен бирү, аннан мәхрүм итү, яңадан торгызу буенча һәм Россия Федерациясе Спорт министрлыгына спорт исемнәрен, «бөтенроссия категорияле спорт хөкемдары» квалификация категориясен бирү, мәхрүм итү һәм яңадан торгызу өчен тәкъдимнәр юллау буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына 6 нчы кушымта
(тәкъдим ителә торган форма)

| **ТӘКЪДИМ** | **СМК, 1 разряд**<br>Сайларга кирәк | | | | Блокта 2 нөсхә фото<br>(3×4 см) |
|---|---|---|---|---|---|
| Спорт төре | | | | | |
| Фамилиясе | | Исеме | | | |
| Атасының исеме | | Туган көне | көн | ай | ел |
| | | | | | |
| Республика, край, өлкә, округ | | Шәһәр (авыл, бистә) | | | |
| БИФСҖ | | Спорт мәктәбе | <u>БЯСМ, БЯОРСМ, ЮСОМ</u><br><u>кирәкмәгенне сызарга</u> | | |
| Белеме | | Физик тәрбия буенча белеме | | | |
| Уку (эш) урыны, вазыйфасы | | | | | |
| Өй адресы | | | | | |
| Гамәлдәге разряд | Бирелү яки Раслау вакыты | Спортчыны әзерләгән тренерларның Ф.И.А.и. | | | Тренер категориясе |
| | | | | | |
| | | | | | |
| | | | | | |
| Региональ<br>спорт федерациясе | | | Спортның хәрби-гамәли һәм хезмәти-гамәли төрләре өчен структур подразделение<br>______________________________<br>(республика, край, өлкә, округ) | | |
| М.У.<br><br>**Җитәкче**<br>(имза) | | | М.У.<br><br>**Җитәкче**<br><br>__________<br>(имза) | | |
| дата | | | дата | | |

| **ТӨП КҮРСӘТКЕЧЛӘР (нормативлар)** | | | |
|---|---|---|---|
| Башкару көне<br>көн, ай, ел | Ярышлар атамасы<br>(дисциплиналар, авырлык, катнашучылар саны) | Ярышларның рангы, категориясе | Күрсәтелгән нәтиҗә |
| | | | |
| | | | |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | | | |
| | | | |
| | | | |
| | | | |
| | | | |
| | | | |
| | | | |

| Хөкемдарның вазыйфасы | Фамилиясе, инициаллары | Шәһәр | Хөкемдарлык категориясе |
|---|---|---|---|
| | | | |
| | | | |
| | | | |
| | | | |
| | | | |

Белешмәлек:

ББСК нигезендә (яңа ББСК 2017 елның 2 апреленнән гамәлдә):

1. Документлар тапшыру вакыты билгеләп куелган нормаларны үтәгәннән соң 4 ай дәвамында.
2. СМК разрядын үтәү өчен хөкемдарлар бригадасы – түбәндәге саннан ким булмаска тиеш: югары категорияле 1 кеше, 1 категорияле – 2 кеше.
3. 1 разрядны үтәү өчен хөкемдарлар бригадасы – түбәндәге саннан ким булмаска тиеш: 1 категорияле 2 кеше, 2 категорияле – 1 кеше.
4. Катнашучылар, команда, көрәш һ.б.ның саны туры килү.
5. Спорт төрләрен исәпкә алган хәлдә яшь таләпләрен үтәү.
6. Спорт разрядының гамәлдә булу вакыты: СМК – 3 ел, 1 разряд – 2 ел.
7. Спорт төрләре буенча квалификация таләпләре РФ Спорт министрлыгы сайтында: http://minsport.gov.ru/sport/high-sport/edinaya-vserossiyska/ адресы буенча урнаштырылган.

*Спорт разрядын үтәү турындагы боерыклар ТР ЯЭСМ сайтында (Физик тәрбия һәм спорт. Бүләкләү турында боерыклар бүлегендә) урнаштырыла.

«Спорт мастерлыгына кандидат» һәм «беренче спорт разряды» спорт разрядларын, «беренче категорияле спорт хөкемдары» квалификация категориясен бирү, аннан мәхрүм итү, яңадан торгызу буенча һәм Россия Федерациясе Спорт министрлыгына спорт исемнәрен, «бөтенроссия категорияле спорт хөкемдары» квалификация категориясен бирү, мәхрүм итү һәм яңадан торгызу өчен тәкъдимнәр юллау буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына 7 нче кушымта
(тәкъдим ителә торган форма)

Татарстан Республикасы Спорт министрлыгы

**Спорт исеме һәм спорт разрядыннан мәхрүм итү һәм торгызу турында**
**Гариза**

1.____________________________________________________
(фамилия, исем, ата исеме (булган очракта),
2.____________________________________________________
спортчының туган көне
3.___________________________________________________
(Оешманың спорт разряды, исем бирү турында документ дата һәм номеры)
4.__________________________________________________
_______________________________________________________
(спорт разряды, исеме, квалификация категориясеннән мәхрүм итү һәм торгызу өчен сәбәпләрне раслый торган мәгълүмат (мәхрүм итү һәм торгызу өчен нигезләмәләрне раслый торган документларны теркәп)

__________________________________________________________________________________________
Үтенеч кәгазен юллый торган оешманың вәкаләтле затының вазыйфа атамасы, имзасы фамилия һәм инициаллары

--------------------------------
<*> Үтенеч җибәрә торган оешма (региональ спорт оешмасы) бланкында теркәлә.

Гаризаны теркәү турында билге №  ________________________
дата

«Спорт мастерлыгына кандидат» һәм «беренче спорт разряды» спорт разрядларын, «беренче категорияле спорт хөкемдары» квалификация категориясен бирү, аннан мәхрүм итү, яңадан торгызу буенча һәм Россия Федерациясе Спорт министрлыгына спорт исемнәрен, «бөтенроссия категорияле спорт хөкемдары» квалификация категориясен бирү, мәхрүм итү һәм яңадан торгызу өчен тәкъдимнәр юллау буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына 8 нче кушымта
(тәкъдим ителә торган форма)

Татарстан Республикасы Спорт министрлыгы

**Спорт хөкемдары категориясеннән мәхүм итү һәм торгызу турында**
**Гариза**

1.______________________________________________
(фамилия, исем, ата исеме (булган очракта),
2.______________________________________________
спортчының туган көне
3.______________________________________________
(Оешманың спорт разряды, исем бирү турында документ дата һәм номеры)
4.______________________________________________

________________________________________________
(спорт хөкемдары квалификация категориясеннән мәхрүм итү һәм торгызу өчен нигезләмәләрне раслый торган мәгълүмат (мәхрүм итү һәм торгызу өчен нигезләмәләрне раслый торган документларны теркәп)

________________________________________________

________________________________________________

Үтенеч кәгазен юллый торган оешманың вәкаләтле затының вазыйфа атамасы, имзасы фамилия һәм инициаллары

--------------------------------
<*> Үтенеч җибәрә торган оешма (региональ спорт оешмасы) бланкында теркәлә.

Гаризаны теркәү турында билге № ________________________
дата

«Спорт мастерлыгына кандидат» һәм «беренче спорт разряды» спорт разрядларын, «беренче категорияле спорт хөкемдары» квалификация категориясен бирү, аннан мәхрүм итү, яңадан торгызу буенча һәм Россия Федерациясе Спорт министрлыгына спорт исемнәрен, «бөтенроссия категорияле спорт хөкемдары» квалификация категориясен бирү, мәхрүм итү һәм яңадан торгызу өчен тәкъдимнәр юллау буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына 9 нчы кушымта
(тәкъдим ителгән форма)

Татарстан Республикасы Спорт министрлыгы

________________________
(оешма атамасы, оешма җитәкчесенең яки оешма вәкиленең ФИА.и.)

**Техник хатаны төзәтү турында**
**гариза**

Дәүләт хезмәте күрсәткән чакта киткән хата турында хәбәр итәм: ____________________________________________________________________

(хезмәт атамасы)

Язылган:_____________________________________________________________________
____________________________________________________________

Дөрес мәгълүмат түбәндәгечә:_______________________________________
_____________________________________________________________________

Җибәрелгән техник хатаны төзәтүне һәм дәүләт хезмәте нәтиҗәсе булган документка тиешле үзгәрешләр кертүне сорыйм.

Түбәндәге документларны терким:

1.

2.

3.

Техник хатаны төзәтүдән баш тарту турында карар кабул иткән очракта әлеге карарны түбәндәге ысул белән юллавыгызны сорыйм:

_______________________ e-mail адресына электрон документ юллап;

карарның кәгазьдә расланган нөсхәсен _____________________________________________________________________

адресы буенча почта аша юллап.

Үземнең, шулай ук мин тәкъдим итә торган затның шәхси мәгълүматларын эшкәртүгә (шәхси мәгълүматларны җыю, систематизацияләү, саклау, тәгаенләү (яңарту, үзгәртү), куллану, тарату (шул исәптән бирү), шәхси үзенчәлекләрен юкка чыгару, тыю, шәхси мәгълүматларны юкка чыгару, шулай ук муниципаль хезмәт күрсәтү кысаларында шәхси мәгълүматларны эшкәртү өчен кирәк башка гамәлләрне), шөл исәптән автоматлаштырылган режимда, дәүләт хезмәтен күрсәтү максатында дәүләт хезмәтен күрсәтә торган орган тарафыннан алар нигезендә карар кабул

итүне дә кертеп, ризалыгымны бирәм.

Әлеге имзам белән гаризага кертелгән һәм минем шәхескә һәм мин тәкъдим итә торган затка карый торган мәгълүмат, шулай ук минем тарафтан түбәндә кертелгән мәгълүматның хаклыгын раслыйм. Гаризага теркәлгән документлар (документларның күчермәләре) Россия Федерациясе законнары тарафыннан билгеләнгән таләпләргә туры килә, гариза биргән вакытка әлеге документлар гамәлдә һәм дөрес мәгълүматка ия.

Миңа күрсәтелгән дәүләт хезмәтенең сыйфатын бәяләү буенча ____________ номеры аша фикер алуда катнашуга ризалыгымны бирәм.

_______________ ___________________ ( _________________)

(дата)

(имза) (Ф.И.А.и.)

Кушымта (белешмә)

**«Спорт мастерына кандидат» һәм «беренче спорт разряды» спорт разрядларын, «беренче категория спорт хөкемдары» квалификация категориясен бирү, мәхрүм итү, яңадан торгызу һәм һәм Россия Федерациясе Спорт министрлыгына спорт исемнәре һәм «Бөтенроссия категорияле спорт хөкемдары» квалификация категориясе бирү, мәхрүм итү һәм яңадан торгызу өчен тәкъдим итүләр юллау өчен буенча дәүләт хезмәте күрсәтү өчен җаваплы органнарның һәм вазыйфаи затларның реквизитлары**

**Татарстан Республикасы Спорт министрлыгы**

| Вазыйфасы, Ф.И.А.и. | Телефон | Электрон адресы |
|---|---|---|
| Министр Леонов Владимир Александрович | 222-81-02 | minsport@tatar.ru |
| Министрның беренче урынбасары Шәйхетдинов Хәлил Хәмит улы | 222 -81-09 | Halil.Shayhutdinov@tatar.ru |
| Югары казанышлар спортын үстерү бүлегенең әйдәп баручы киңәшчесе Вафин Раиф Ришат улы | 222-81-44 | Raif.Vafin@tatar.ru |

**Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппараты**

| Вазыйфасы, Ф.И.А.и. | Телефон | Электрон адресы |
|---|---|---|
| Сәламәтлек саклау, спорт һәм сәламәт яшәү рәвеше формалаштыру мәсьәләләре идарәсе башлыгы Шакирова Гүзәл Рәис кызы | 264-77-84 | Guzel.Shakirova@tatar.ru |